| Сайлауга һәм сайлануга хокук | 60 |
| Россия Федерациясе гражданлыгына хокук. Ирекле хәрәкәт итәргә, килү һәм яшәү урынын сайларга | 141 |
| Дәүләт һәм муниципаль органнарга мөрәҗәгать итәргә хокук | 202 |
| Торакка хокук | 185 |
| Социаль тәэминатка хокук | 285 |
| Хезмәткә хокук | 89 |
| Сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокук | 120 |
| Белем алуга хокук | 211 |
| Гаилә, аналар, аталар һәм балаларны яклауга хокук | 63 |
| Әйләнә-тирә мохиткә һәм җиргә хокук | 30 |



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 162 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| Тоткарланучылар, шикләнелүчеләр һәм гаепләнүчеләр хокуклары | 281 |
| Зыян күрүчеләр хокуклары | 37 |
| Җәза үтәүчеләрнең хокуклары | 298 |
| Административ хокук бозулар эшләре буенча производствода кеше хокукларын яклау | 7 |
| Суд карарларына шикаять бирү | 25 |
| Законлы көченә кергән актларны башкарганда кеше хокукларын яклау | 139 |
| Хәрби хезмәткә алганда кеше хокукларын, хәрби хезмәткәрләрнең хокукларын яклау | 671 |
| Торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендәге мәсьәләләр | 329 |
| Хокук саклау органнарына шикаятьләр | 114 |
| Финанслар, хуҗалык эшчәнлеге һәм башка мәсьәләләр | 913 |

Торак-коммуналь өлкәдә 2024 елда гражданнар кагылган мәсьәләләр елдан-ел үзгәрми диярлек. Һәм мөрәҗәгатьләр саны, кагыйдә буларак, тотрыклы рәвештә югары булып кала.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкил тарафыннан коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты тиешенчә булмау (салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүдә өзеклекләр, суның түбән температурасы), гомумйорт мөлкәтен канәгатьләнерлек дәрәҗәдә тотмау (дымлылыкның артуы, диварларның катуы, канализация исе, вентиляция системасының бозылуы), идарәче компанияләр, ширкәтләр хезмәткәрләренең гамәлләре (гамәл кылмаулары) турындагы, торак милекчеләре һәм милек белән идарә итүнең башка рәвешләре (тиешенчә ремонтламау, вакытында ремонтламау, коммуналь аварияләрне бетерү срокларын сузу), тарифларны исәпләү, коммуналь хезмәт күрсәтү өчен түләүләр исәпләү һәм торакны карап тоту тәртибен бозу турындагы мөрәҗәгатьләр каралды.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, хокукларның әлеге категориясенә кагылышлы мөрәҗәгатьләрнең аз өлеше торак белән тәэмин ителеш мәсьәләләренә кагылды: монда ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү, инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә алу мәсьәләләре.

Социаль тәэмин итү өлкәсендәге мөрәҗәгатьләр пенсия белән тәэмин итү, инвалидларны социаль тәэмин итү («уңайлы мохит» булдыру, кешене инвалид дип тану, техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин ителү, реабилитацияләүнең һәм абилитацияләүнең индивидуаль программасына үзгәрешләр кертү, шифаханә-курорт дәвалануына юллама рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алмау), хезмәткәрләрнең гамәлләре (гамәл кылмау) мәсьәләләренә кагылды.

Узган ел белән чагыштырганда хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсенә кагылышлы мөрәҗәгатьләр саны 46% ка артты. 2024 елда хезмәт өлкәсендә Вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләргә анализ шуны күрсәтә: нигездә гражданнар хезмәт хакын түләмәү, эштән чыгарырга мәҗбүр итү, законсыз эштән чыгару, хезмәт конфликтлары, эшкә урнашу проблемалары буенча мөрәҗәгать иткәннәр.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 163 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнар тарафыннан дару препаратлары белән тәэмин ителмәү һәм тиешенчә медицина ярдәме күрсәтмәү белән бәйле проблемалар очрый.

Мәгариф өлкәсендә уку йортларында уку процессын оештыруга, белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлы вәзгыять булуга шикаятьләр килде. Шулай ук мөмкинлекләре чикләнгән балаларга белем бирү, белем бирү учреждениеләренә керүдә ярдәм күрсәтү, белем бирү-сәламәтләндерү лагерьларында «инклюзив балалар ялын» оештыру, белем бирү учреждениеләренә транспорт белән барып җитү, яңа уку йортлары төзү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр килү дәвам итте.

2024 елда гаилә хокукларын яклау өлкәсендә гражданнар баланы тәрбияләү һәм матди карап тору буенча соңгы бурычларын үтәмәүгә бәйле рәвештә элеккеге ир белән хатынны ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүдә, балалар яки оныклар белән аралашу мөмкин булмау турында, ата-ана хокукларын торгызу турында, балаларның кайда булуы һәм аларның сәламәтлек торышы турында, бала язмышы өчен борчылулар турында һ.б. сорадылар.

Уңайлы әйләнә-тирә мохиткә һәм җиргә хокук белән бәйле мәсьәләләр саны кимеде. 2024 елда гражданнар тарафыннан бу тематика буенча мөрәҗәгатьләрдә атмосфера һавасын пычрату, җир бәхәсләре, рөхсәтсез чүплекләр, су объектларын саклау һ. б. мәсьәләләр күтәрелде.

Россия Федерациясе субъектларындагы вәкаләтле вәкилләр җинаять суд эшләрен алып баруда катнашмасалар да, җинаять суд эшләрен башкаручы органнарның вазыйфаи затлары даирәсенә кермәсәләр дә, Вәкаләтле вәкил шикаятьләрне карый торган субъектлар даирәсенә шунысын билгеләп үтәргә кирәк, җинаять процессында, мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын яклау өлкәсендә кергән мәсьәләләр саны, элеккечә үк тотрыклы рәвештә югары булып кала бирә. Гражданнар җинаять эшләре кузгатуның нигезсезлеген; җинаять суд эшләрен алып бару срокларының озынлыгын күрсәттеләр; тикшерү гамәлләренең законлылыгы; җинаять эшләре буенча хөкем карарларының законлылыгы, нигезлелеге һәм гаделлеге һ.б.; медицина һәм матди-көнкүреш тәэмин ителешенең канәгатьләнерлек булмавына, җинаять-үтәтү системасы хезмәткәрләренең хокуксыз гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук алга таба җәзаны үтәү өчен күчерү һәм вакытыннан алда азат итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать иттеләр.

Ел саен Вәкаләтле вәкилгә авыр тормыш хәлендә калган гражданнардан мөрәҗәгатьләр килә. Бу кеше хокукларын конкрет бозу булмаган вәзгыять, ләкин, кызганычка каршы, шулай килеп чыккан, кеше бәлагә эләккән. Канунибызның маддәсе нигезендә мондый мөрәҗәгатьләр эшкә алынмаса да, безнең тарафтан һәртөрле ярдәм күрсәтү буенча эш алып барыла. Хокук яклау эшчәнлегенең өстәмә юнәлеше формалашуы турында расларга мөмкин. Мондый мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгатьләрнең гомуми санына йогынты ясамыйлар, күплекне тәшкил итмиләр, әмма Вәкаләтле вәкилнең эшен яңа эчтәлек белән тулыландыралар. Мондый мөрәҗәгатьләр шәфкатьлелекне, игелеклелекне, кешелеклелекне сакларга ярдәм итә.

Мисалларның берсе итеп, Әлмәттә яшәүче, травма нәтиҗәсендә көчле туктаусыз авыртулар кичерүче һәм чит кешеләр ярдәмендә хәрәкәтләнергә мәҗбүр булган гр Г. Яшәү өчен кирәкле ихтыяҗларга пенсия түләүләре җитмәү сәбәпле, «Татнефть» хәйрия фонды директоры адресына вәкаләтле вәкил тиешле ярдәмне, шул исәптән матди ярдәмне дә, күрсәтү мөмкинлеген карауны сорап мөрәҗәгать итте. Вәкаләтле



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 164 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

вәкилнең үтенечнамәсен игътибарга алып, «Татнефть» ГАҖнә керүче мөрәҗәгатьләрне карау комитеты утырышында өй шартларында дәвалану өчен дару препаратлары һәм терапевтик аппаратура сатып алуга 50 мең сум күләмендә иганәчелек ярдәме күрсәтү турында карар кабул ителде.

Гавами хакимият органнарының гражданнар белән цифрлы хезмәттәшлеге тенденциясе актив үсә. Әлеге өлкәдә төрле электрон сервислар һәм платформалар актив үсештә.

2013 елдан Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы (алга таба - «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасы) эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

2024 елда «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында, барлык статуслардан кире кайтарылган белдерүләрне исәпкә алып, 97 898 мөрәҗәгать басылып чыкты, бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 7% ка кимрәк («Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы белән интеграциясе өзелүгә бәйле рәвештә), шулардан: 76 118 мөрәҗәгать хәл ителгән (78%), 15 896 мөрәҗәгать буенча эшләр планлаштырылган (16%), 4 594 мөрәҗәгать буенча нигезле рәвештә кире кагылган (6%), 1 290 мөрәҗәгать (21%) эштә.

Системадан файдаланучылар иң актив рәвештә «Төзекләндерү һәм инфраструктура» – 41 568, «Юллар» – 34 315, «Торак-коммуналь хуҗалык» – 8 954, «Каты коммуналь калдыклар» – 4 318, «Транспорт» – 2 501, «Экология» – 1 371, «Сәүдә» – 1 178, «Сәламәтлек саклау» – 1 073 һәм башка юнәлешләр буенча мөрәҗәгать иттеләр.

Елдан-ел «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, республика халкында әлеге интернет-ресурсның, республика һәм җирле дәрәҗәдә гражданнар мөрәҗәгатьләрен хәл итү буенча гражданнар һәм җирле үзидарә органнары арасында турыдан-туры элемтә каналларының берсе буларак кирәклеген күрсәтә.

2024 елда «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасына хисап чорында (шул исәптән кабат карау өчен) гражданнардан барлыгы 99 788 мөрәҗәгать һәм хәбәр кергән, бу узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 66% ка күбрәк.

Портал кулланучыларыннан, гражданнардан иң күп мөрәҗәгатьләр һәм хәбәрләр: сәламәтлек саклау (медицина электрон документларын алу һәм табибка электрон язылу) мәсьәләләре буенча - 52 066, укучының электрон көндәлегенә керү проблемасы - 24 951, территорияне комплекслы төзекләндерү – 5 733, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү – 3 648, автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту – 3 189, хәрби хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының мөрәҗәгатьләре – 1 898, маршрут хәрәкәте схемасын (графигын) бозу, йөртүчеләрнең һәм кондукторларның үз-үзләрен дөрес тотмау, транспорт маршрутын яисә графигын үзгәртү тәкъдиме - 616, күп балалы гаиләнең электрон таныклыгын алу - 356.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эш Вәкаләтле вәкил тарафыннан даими рәвештә, аның мөмкин булган теләсә нинди чагылышларында алып барыла.

2025 елга бурычлар арасында Вәкаләтле вәкил гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләгәндә түбәндәгеләрне аерып күрсәтә:



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 165 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- гражданнар мөрәҗәгатьләрен, законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәрне карау, тематик докладлар әзерләү нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр һәм бәяләмәләр әзерләү һәм дәүләт органнарына җибәрү практикасы киңәйтеләчәк.

- дәүләт органнары һәм гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек: уртак тематик кабул итүләр үткәрү, шикаятьләр буенча тикшерүләр үткәрү, кеше хокуклары өлкәсендәге актуаль проблемалар турында фикер алышу дәвам иттереләчәк.

- Россия төбәкләрендәге һәм чит илләрдәге вәкилләрнең уңай тәҗрибәсе өйрәнеләчәк.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 166 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

# 2-НЧЕ БҮЛЕК. МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯДӘ КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ГАИЛӘ ӘГЪЗАЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

## 2.1. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының хокукларын яклау

Россия Федерациясе Кораллы көчләре Башкомандующие В.В. Путин Украина территориясендә махсус хәрби операция үткәрү турында игълан иткән көннән алып өч елга якын вакыт узды. Махсус хәрби операция бурычларын хәл итү һәм анда катнашучыларга гарантияләр тәэмин итү өчен бөтен ил берләште. Бу эшчәнлек күп кенә гавами хакимият органнары һәм гражданнар җәмгыяте институтлары өчен өстенлекле булды.

Махсус хәрби операция башланганнан бирле Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре хәрбиләр һәм аларның гаиләләре белән эшләүнең барлык мәсьәләләренә һәм формаларына кушылды.

2022 елдан Вәкаләтле вәкилгә хәрбиләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан 7700 дән артык мөрәҗәгать кергән. Хисап елында әлеге тематика буенча Вәкаләтле вәкил Аппаратына 644 мөрәҗәгать кергән, шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре.Бергә хәл итәбез» бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының кире элемтә платформасы аша - 36, «Халык контроле» системасы аша -165.

Вәкаләтле вәкил тарафыннан 2022-2024 елларда каралган мөрәҗәгатьләрнең сан күрсәткечләрен һәм эчтәлеген бәяләгәндә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашырганда барлыкка килгән проблемаларның эчтәлегендә билгеле бер үзгәрешләрне билгеләп үтәргә мөмкин. Әгәр 2022 елда мөрәҗәгать итүчеләрдә күбесенчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру, гражданнарга кичектерү бирү белән бәйле мәсьәләләр торса, 2024 елда нигездә социаль ярдәм чаралары күрсәтү, медицина ярдәме күрсәтү, шулай ук хәрби хезмәткәр статусын билгеләү, тикшерү уздыру белән бәйле мәсьәләләр туды.

Вәкаләтле вәкилгә килгән барлык мөрәҗәгатьләр мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә, хәрбиләрнең туганнары, якыннары белән даими элемтәдә булганда каралды.

### Социаль ярдәм чараларын күрсәтү

Татарстан Республикасы Рәисе Р. Н.Миңнеханов 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында болай дип ассызыклады: «Безнең сугышчылар Ватанны алгы сызыкта саклаган вакытта төп бурыч – аларга якыннары өчен ышаныч һәм тынычлык тәэмин итү. Барлык билгеләнгән ярдәм чаралары һәм ташламалар тайпылышсыз бирелергә тиеш».

Федераль социаль ярдәм чаралары белән беррәттән, республикада социаль ярдәмнең өстәмә чаралары да уңышлы гамәлгә ашырыла. Мәсәлән, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына, хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре арасыннан һәм махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) гражданнарның 18 яшькә җитмәгән һәр баласына 20 мең сум күләмендә бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү; йорт биләмәсе чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендә газ җиһазлары сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга 100



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 167 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

мең сум субсидия. Яңа туган балалары булган катнашучыларның гаиләләре сабыйлар өчен кирәк-ярак белән тәэмин ителә.

Гаилә әгъзаларына:

60 һәм 55 яшьтәге гражданнарга ( ир-атлар һәм хатын-кызлар) һәм пенсионерларга шифаханә-курорт дәвалануына юлламалар белән тәэмин ителгәндә беренче чираттагы хокук бирелә;

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм I һәм II төркем инвалидларга өйдә социаль хезмәтләр түләүсез күрсәтелә;

инвалид балаларга мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренә социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә өстенлекле хокук бирелә.

Махсус хәрби операциядә катнашып һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларына 2,0 млн сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелә.

Шунысы куанычлы: республиканың муниципаль берәмлекләрендә 2022 елдан башлап махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре өчен ташламалар һәм ярдәм чаралары гамәлгә ашырыла. 2023 елның 1 гыйнварына муниципаль берәмлекләрдә, шәһәр округларында инде махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына 14 төрле 1360 ташлама һәм ярдәм итү чаралары каралган иде. 2024 елда ул 2560 ка артты.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә күрсәтелә торган ярдәм чаралары ташламаларның һәм финанс ярдәменең киң спектрын үз эченә ала: матди ярдәм, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт өчен түләүгә ташламалар, социаль хезмәт күрсәтү, гражданнарны үзара салым түләүдән азат итү һәм башка әһәмиятле чаралар.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына түләүләр һәм ярдәм чаралары мәсьәләләре Вәкаләтле вәкилнең даими игътибар үзәгендә тора.

Әлеге тематика буенча мөрәҗәгатьләрнең шактый өлеше хәрби хезмәткәрләргә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүгә бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләүләр бирү тәртибенә һәм срогына кагылган. Мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре шуны күрсәтә: күпчелек очракта каралган түләүләрне вакытында алмауның сәбәпләре хәрби частьтән хәрби хезмәткәрне шәхси составка алу турында мәгълүмат булмау һәм (яисә) хәрби хезмәткәрнең шәхси мәгълүматларында техник хаталар җибәрелү. Мөрәҗәгатьләрнең күрсәтелгән категориясе безнең тарафтан Хәрби комиссариат белән берлектә каралды.

Мисал өчен, 2024 елның июлендә гражданнарны шәхси кабул итү кысаларында, Вәкаләтле вәкил адресына Яр Чаллы шәһәреннән хәрби хезмәткәрнең хатыны, ире хәрби хезмәт узу турында контракт төзүгә бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган 360 000 сум күләмендә түләү алмау мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгать итүченең ире, хәрби частьтән шәхси составка алынуы турында мәгълүмат булмау сәбәпле, ярты елдан артык әлеге түләүне ала алмаган. Күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карап, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары адресына килеп туган хәлгә үз позициясен бәян итеп, мөрәҗәгать итте. Хезмәт министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән уртак эш нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчең иренә бер мәртәбә түләү бирелде. Хезмәт министрлыгы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән бергәләп эшләү



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 168 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

йомгаклары буенча бер тапкыр түләнә торган түләү мөрәҗәгать итүченең иренә күчерелде.

Татарстан Республикасында хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына адреслы ярдәм күрсәтү өчен «Үзебезнекеләр турында кайгырту» программасы гамәлдә. Махсус хәрби операция темасына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр белән актив эш алып барыла. Алар «Үзебезнекеләр турында кайгырту» сайты, 117 кайнар элемтәсе, «Халык контроле» һәм «Инцидент Менеджмент» системасы аша килә. Без кире элемтә каналлары аша килгән хәбәрләргә даими рәвештә анализ үткәрдек.

06.11.2023 - 01.10.2024 «СВОИХ турында ЗАБОТА республика программасы кысаларында СВО катнашучылары һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (117, ТР "Халык Контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, "Инцидент Менеджмент", "ЗАБОТА О СВОИХ" сайты) 18 меңнән артык мөрәҗәгать эшләнгән, алар: 10303 (56%) - федераль чаралар (югалган, һәлак булган, федераль түләүләр), 44 75 ( 41%) - мәгълүмат-белешмә характердагы мәсьәләләр, 552 (553%) - республика ярдәме чаралары буенча, дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына адреслы ярдәм чаралары күрсәтү өчен җаваплы чаралар күчерелгән.

2023 елның 6 ноябреннән 2024 елның 1 октябренә кадәр – «Үзебезнекеләр турында кайгырту» республика программасы кысаларында махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (кайнар линия телефоны 117, «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасы, «Инцидент менеджмент», «Үзебезнекеләр турында кайгырту» сайты) 18 меңнән артык мөрәҗәгать каралган, алар: 10303 (56%) – федераль ярдәм чараларына кагылышлы (югалганнар, һәлак булганнар, федераль түләүләр), 7544 (41%) – мәгълүмати-белешмә характерындагы мәсьәләләр, 552 (3%) – республика ярдәм чараларына кагылышлы, алар адреслы ярдәм күрсәтү өчен җаваплы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына җибәрелде.

Анализ нәтиҗәләрен тикшерү, шулай ук гражданнар сораулары буенча системалы тәкъдимнәр эшләү максатларында, Вәкаләтле вәкил «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы вәкилләре, дәүләт хакимияте органнары, муниципаль берәмлекләр вәкилләре белән эшлекле киңәшмәләр уздырды.

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларының белемгә хокукларын яклау**

Хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт бурычларын) башкарганда һәлак булган яисә гарипләнгән (яраланган, җәрәхәтләнгән, контузия алган) яисә чир алган хәрбиләрнең, махсус хәрби операция ветераннары (катнашучылары) балалары, шәхси мәгълүматны яклау таләпләрен һәм психологик-педагогик озата баруны оештыруда этик таләпләрне үтәп, зур игътибарга мохтаҗ.

2023 елда Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгы, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән берлектә, мәктәпкәчә мәгариф, гомуми белем бирү, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм махсус хәрби операциядә белем алучы ветераннар (катнашучылар) балаларын (катнашучылар) югары белем бирү мәгариф оешмаларында озату алгоритмнары шундый балаларга кирәкле ярдәм күрсәтү максатларында, шул исәптән



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 169 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

психологик (Россия Мәгариф министрлыгының 2023 елның 11 августындагы АБ-3386/07 номерлы хаты) эшләнде һәм регионнарга җибәрелде. Әлеге мәсьәләнең мөһимлеген исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Мәгариф министрлыгы) мәктәп психологларын махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары белән эшләргә мәҗбүри өйрәтүне оештырырга тәкъдим итә.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары мәнфәгатьләрендә, Вәкаләтле вәкил тарафыннан 2022 елда ук, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына белем бирү өстенлекләрен билгеләү турында тәкъдим җибәрелгән иде, ул 2023 елда хупланды.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм аларның балаларының аерым квота чикләрендә федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм җирле бюджетлар акчалары хисабына бакалавриат һәм специалитет программалары буенча укытуга хокукларын ныгыту өлешендә үзгшрешләр кертелде.

Хисап елында күрсәтелгән махсус квота буенча республиканың югары белем бирү мәгариф оешмаларына махсус хәрби операциядә катнашучының 370 баласы кабул ителде.

Узган елда Вәкаләтле вәкил шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларының федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән түләүле укудан бушлай укуга күчү хокукын тормышка ашыруга яисә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың үз акчалары исәбеннән укытуга булышлык күрсәтте.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил адресына гражданка М.нан «Казан (Идел буе) федераль университеты» дизайн һәм пространство сәнгате институтында (алга таба – КФУ) белем алучы кызын түләүле укудан түләүсез укуга күчерүдә ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать килгән. Мөрәҗәгать итүченең кызы махсус хәрби операциядә катнашучының баласы булуын исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүченең кызын түләүсез укытуга күчерү мөмкинлеген карау турындагы үтенеч хаты белән КФУ ректоры адресына мөрәҗәгать итте. Безнең хат җитәкчелек тарафыннан уңай хәл ителде, түләүле белем бирү хезмәтләренең бәясе 100% ка киметелде.

**Хәрби хезмәткәрләргә медицина ярдәме күрсәтү**

Вәкаләтле вәкилнең хокук яклау эшчәнлегендә хәрби хезмәткәрләрнең медицина ярдәменә хокукларын үтәү мәсьәләләренә зур игътибар бирелде.

Ел дәвамында Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «354 хәрби клиник госпитале» базасында, Вәкаләтле вәкил берничә тапкыр хәрби хезмәткәрләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы җитәкчесе, Татарстан Хәрби комиссариаты, Казан гарнизоны Хәрби прокуратурасы вәкилләре белән бергә кабул итте.

Ел башында Вәкаләтле вәкил адресына хәрби хезмәткәрләрдән отпуск вакытында яшәү урыны буенча медицина оешмаларында медицина ярдәме алу мөмкинлеге турында мөрәҗәгатьләр кергән. Хәрби хезмәткәрләр медицина ярдәме



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 170 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

сорап Россия Федерациясе Оборона министрлыгының ведомство госпитальләренә генә мөрәҗәгать итә алганнар, бу алар өчен шактый уңайсызлыклар тудырган.

Махсус хәрби операция үткәрү чорында әлеге мәсьәләнең аеруча актуальлеген исәпкә алып, 2024 елның августында Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н.Москалькова адресына мәҗбүри медицина иминияте полисының гамәлдә булуын хәрбиләргә дә куллану мәсьәләсен карау турында тәкъдим җибәрде. Безнең тәкъдимнәр уңай чишелеш тапты.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 24 октябрендәге 1423 номерлы карары белән отпусктагы хәрби хезмәткәрләргә махсус хәрби операция уздыру чорында теләсә кайсы уңайлы дәүләт сырхауханәсендә беренчел медицина-санитария ярдәме алу хокукы бирелде. Әлеге тәртип махсус хәрби операция үткәрү вакытында гамәлдә булачак. Карар мохтаҗ хәрбиләр өчен медицина ярдәме алу мөмкинлеген арттырырга мөмкинлек бирде.

Республиканың медицина оешмаларында махсус хәрби операциядә катнашучыларга чиратсыз медицина ярдәме күрсәтү оештырылган. Барлык медицина оешмаларында махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина ярдәмен оештыру мәсьәләләре буенча җаваплы затлар билгеләнде.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына медицина ярдәме күрсәтү буенча җаваплылык үзәге итеп, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» дәүләт учреждениесе, Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» дәүләт учреждениесе (алга таба – госпитальләр), «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының республика клиник хастаханәсе» « М.Н.Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» билгеләнде.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында махсус хәрби операция барышында яраланган Россия Федерациясе Кораллы көчләренең хәрби хезмәткәрләренә медицина ярдәме күрсәтү максатларында «хирургия», «травматология һәм ортопедия», «абдоминаль хирургия», «нейрохирургия», «реанимация», «медицина реабилитациясе» профильләре буенча 460 ятак бирелгән: «Республика клиник хастаханәсе» – 300 урын, «М.Н. Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» – 100 урын, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» дәүләт учреждениесендә 60 урын.

Госпитальләрдә махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан шалтыратулар кабул итү өчен тәүлек әйләнәсе кол-үзәкләр эшли.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 171 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Хәрби-табиб комиссиясен узу һәм сәламәтлек торышы буенча хәрби хезмәт вазыйфаларын башкарудан азат итү мәсьәләләре**

Махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен хәрби-табиб комиссиясен узу һәм алга таба авыру буенча отпуск бирү яисә хәрби хезмәт вазыйфаларын башкарудан азат итү актуаль мәсьәлә булып торды. Хәрби хезмәткәрләр Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьләрендә шулай ук хәрби-табиб комиссиясе карары белән килешмәүләрен белдерделәр, өстәмә тикшерү оештыруда һәм кабат хәрби-табиб комиссиясен үткәрүдә ярдәм күрсәтүләрен сорадылар.

Шулай итеп, Вәкаләтле вәкил адресына хәрби хезмәткәрнең хәрби хезмәткә яраклылыгын билгеләү өчен аңа өстәмә медицина диагностикасы үткәрүдә ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча Казанда яшәүче Ф. хатыны мөрәҗәгать иткән. 2023 елның 2 августында хәрби хезмәткәр Ф. хәрби операция уздыру зонасында булганда снаряд шартлау нәтиҗәсендә яралана, шуңа бәйле рәвештә төрле хәрби-медицина учреждениеләрендә дәвалана. Медицина тикшерүе һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча хәрби-табиб комиссиясе карары белән хәрби хезмәткәргә хәрби хезмәткә яраклылыгы чикле булган «В» категориясе бирелә. Шул ук вакытта организмы эшчәнлеге бозылуга китергән авырулар булу аңа алга таба хәрби хезмәт үтәргә комачаулаган. Ул өстәмә дәвалануга һәм тикшеренүгә мохтаҗ булган.

Тәкъдим ителгән медицина документларын игътибар белән өйрәнгәннән соң, хәрби хезмәткәр Ф. ның хокуклары бозылуын күреп, Вәкаләтле вәкил хәрби прокуратура органына һәм Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты А. З. Фәрраховка әлеге вәзгыятьне хәл итүдә ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча, Чита гарнизоны Хәрби прокуратурасы соңгы карар кабул итү өчен Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Хәрби-табиб экспертизасы Баш үзәге»нә (Хабаровск шәһәре) медицина документларын кабат җибәрү турында хәбәр итте.

Хәрби хезмәткәр Ф.ны хәрби хезмәттән азат итү мәсьәләсе хәл ителмәү сәбәпле, Вәкаләтле вәкил Чита гарнизоны хәрби Прокуроры адресына кабат хат юллады. Чита гарнизоны Хәрби прокуратурасы үткәргән тикшерү нәтиҗәсендә хәрби частьнең вазыйфаи затлары тарафыннан хәрби хезмәткәрне хәрби хезмәттән азат итүгә документларның югары хәрби идарә органына вакытында җибәрелмәве ачыкланган, бу Ф. хәрби хезмәткәрнең Россия Федерациясе Кораллы көчләреннән вакытында азат итүгә хокукларын бозуга китергән. Прокуратура органы тарафыннан хәрби часть җитәкчелеге адресына тәкъдимнәр кертелде, анда шулай ук хәрби хезмәткәр Ф.ның Россия Федерациясе Кораллы көчләреннән вакытында азат ителүгә хокукларын бозу буенча кичекмәстән чаралар күрү мәсьәләсе куелды. Прокурорның тәкъдиме канәгатьләндерелде, хәрби часть командиры Ф. хәрбине хәрби хезмәттән азат итү буенча чаралар күрде.

Әлеге хәрби өенә кайткач, аның хокукларын яклауда ярдәм иткән өчен Вәкаләтле вәкилгә рәхмәт белдерде.

**Чираттагы ялга хокук**

Узган елда Вәкаләтле вәкил хәрбиләрнең ялга хокукларын яклау буенча чаралар күрде.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 172 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

2023 елда Федераль Җыенга Юлламасында Россия Президенты В.В. Путин махсус операциядә катнашучыларга ярты ел саен кимендә 14 көн ял итүне тәэмин итәргә кушты.

Кайбер мөрәҗәгатьләрдә гражданнар хәрби хезмәткәргә отпуск бирү мәсьәләсенең озак вакыт хәл ителмәве турында хәбәр иткәннәр.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкилгә Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче хәрби хезмәткәр В. хатыны мөрәҗәгать итте, ул 2023 елның октябреннән махсус хәрби операция уздыру зонасында булган иренә отпуск бирүдә ярдәм итүне сораган. Хәрби хезмәткәрнең биш балигъ булмаган баласы аны өендә көтеп тора. Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты ярдәмендә хәрби хезмәткәргә отпуск бирелде.

**Хәрби хезмәткәр статусын билгеләү мәсьәләләре**

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкилгә махсус хәрби операциядә катнашучыларының гаилә әгъзаларыннан махсус хәрби операция зонасында хәбәрсез югалган хәрбиләрне эзләүдә, шулай ук әсирлеккә эләккәннәрне илгә кайтаруда ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгатьләр керде.

Мондый мөрәҗәгатьләрнең һәрберсе Вәкаләтле вәкил тарафыннан кыска вакыт эчендә каралды, мөрәҗәгать итүчеләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән максималь чаралар күрелде. Эш Россия Федерациясе Оборона министрлыгы һәм Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты белән оператив хезмәттәшлеккә корылды, анда махсус хәрби операция уздыру чорында гражданнарның хокуклары үтәлешен мониторинглау буенча махсус эшче төркем төзелде. Вәкаләтле вәкил гариза бирүчеләр белән даими элемтәдә тора, аларга хәрби хезмәткәрләрнең һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларының кайда булуын билгеләү буенча күрелә торган чаралар турында мәгълүмат җиткерә.

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы һәм Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең уртак гамәлләре нәтиҗәсендә кайбер ватандашларыбызны әсирлектән кайтаруга, шулай ук хәрбиләрнең кайда булуын билгеләүгә ирешелде (аларның саны турындагы мәгълүматны әйтергә ярамый). Без һәрбер хәбәрсез югалган кешенең табылуына шатландык, әниләре һәм хатыннарын кабул иткәндә, алар белән бергә аларның дөреслек өчен көрәшүче туганнары турындагы кабатланмас тарихларын тыңлап еладык.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларыннан мөрәҗәгатьләр алганда, Вәкаләтле вәкил шулай ук муниципаль берәмлекләр җитәкчелегенә һәм «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалына хәрби хезмәткәрнең гаиләсен исәпкә алуны һәм аңа көнкүреш, матди һәм башка тормыш хәлләрен хәл итүдә һәрьяклап ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итте. 2024 елда республиканың муниципаль районнары, шәһәр округлары башлыкларына 180нән артык хат җибәрелде.

Вәкаләтле вәкил җирле үзидарә органнарына гаиләләргә ярдәм иткәннәре, аларга игътибарлы һәм битараф булмаган мөнәсәбәтләре өчен рәхмәт белдерә



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 173 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә ярдәм күрсәтү**

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил муниципаль берәмлекләр, шәһәр округларының мобилизацияләнгәннәрнең гаиләләренә комплекслы ярдәм күрсәтү буенча эшне оештыруга анализ ясады.

Муниципаль берәмлекләрдән бирелгән мәгълүмат мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә һәрвакытта да һәрьяклы комплекслы ярдәм күрсәтелүе турында дәлилләми. Мондый очракларда Вәкаләтле вәкил, мәгълүматларны тулыландыру өчен, муниципаль берәмлекләр, шәһәр округлары җитәкчеләренә кабат мөрәҗәгать итте. Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил тарафыннан Апас, Лениногорск, Алабуга, Яшел Үзән районнары, Казан шәһәренең Совет районы администрациясе, Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе җитәкчеләренә өстәмә хатлар җибәрелде.

2024 елның декабрендә Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре Биектау муниципаль районы башкарма комитетының махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләре белән башкарган эше хакында танышу максатыннан Биектау муниципаль районына барды.

Атна саен Вәкаләтле вәкил гражданнарны шәхси кабул итү кысаларында хәрбиләрнең гаиләләре белән шәхсән очрашты. Махсус хәрби операциядә катнашучы 180нән күбрәк кеше һәм аларның гаилә әгъзалары шәхсән Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итте.

Вәкаләтле вәкил инициативасы белән 2024 елның 26 ноябрендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы һәм Хезмәт министрлыгы белән берлектә махсус хәрби операциядә катнашучыларның аналары белән очрашу оештырылды. Очрашу Әниләр көненә багышланган иде. Әниләр арасында күп балалы, ике улы махсус операция зонасында булганнар, бер үк вакытта уллары гына түгел, оныклары да хезмәт итүчеләр бар иде. Утырыш барышында әниләр махсус хәрби операциясе һәр катнашучысының истәлеген мәңгеләштерү өчен махсус Хәтер китабын булдыру тәкъдимен әйттеләр, хәрби хезмәткәрләр-медиклар аерым билгеләп үтелде, шулай ук медикаментлар белән өстәмә тәэмин итү, хәрбиләр өчен махсус экипировка ясау турында да әйтелде. Чара бик җылы һәм эмоциональ узды, әниләр чиксез ярату һәм горурлык белән уллары турында сөйләделәр.

Республикада махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү эшен координацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.03.2023 № 790-р күрсәтмәсе белән, Татарстан Республикасы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча төбәк ведомствоара комиссия төзелде һәм аның составы расланды. Комиссия утырышларында Вәкаләтле вәкил актив катнашты, инвалид булган махсус хәрби операциядә катнашучылар биләгән торак урыннарны аларның ихтыяҗларына яраклаштыру; хәрби хезмәттән азат ителгән махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын эшкә урнаштыру; махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына психологик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре каралды һәм тиешле йөкләмәләр бирелде.

Мәсәлән, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, муниципаль торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 174 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

тикшерү буенча муниципаль ведомствоара комиссияләр төзү турындагы муниципаль хокукый актларны актуальләштерергә һәм комиссия әгъзалары санын оптимальләштерергә; күрсәтелгән комиссия составына «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалының муниципаль берәмлектәге социаль коодинаторларны кертергә; инвалид булган махсус хәрби операциядә катнашучылар яши торган күпфатирлы йортлардагы махсус хәрби операциядә катнашучылар биләгән торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча, (аларның ихтыяҗларын исәпкә алып(тикшерү өчен комиссиянең чыгуы; тикшерү актын әзерләү, имзалау), муниципаль ведомствоара комиссияләрнең оперативлыгын тәэмин итәргә; инвалид булган махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына торак биналарын шәхси ихтыяҗларга яраклаштыруда булышу өчен гариза бирү мөмкинлеге булу турында мәгълүмат бирергә.

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына психологик ярдәм күрсәтү һәм реабилитацияләү**

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның тыныч тормышка кайтуы еш кына нык борчылу, посттравматик тайпылышлар һәм адаптация проблемалары белән бергә бара.

2024 елның 11 аенда республикада медицина психологлары тарафыннан 783 махсус хәрби операциядә катнашучыга, аларның һәм һәлак булганнарның 1843 гаилә әгъзасына консультацияләр бирелде. Гамәлдәге психологик ярдәм инфраструктурасы 70 медицина-психологик консультация кабинетын үз эченә ала.

Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына (алга таба – Сәламәтлек саклау министрлыгы) махсус хәрби операция тулысынча тәмамланган һәм хәрби операциядә катнашучылар тыныч тормышка кайткан очракта, психологик кабинетлар санын һәм аларның эшен анализлауны тәкъдим итәргә кирәк, дип саный.

Вәкаләтле вәкилнең хокук яклау эшчәнлегендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итү ысулларына игътибар юнәлтелгән.

Хәзерге вакытта республикада махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының дәүләт белән үзара хезмәттәшлегенең бердәм мәгълүмат системасы юк. Бу сорауларның кабатлануына, аларны карау срокларының артуына һәм ведомстволар арасында координациянең җитәрлек булмавына китерә.

Махсус хәрби операциядә катнашуның социаль нәтиҗәләрен объектив бәяләү максатыннан, махсус хәрби операция зонасыннан кайткан затларның исәбен аерым ведомстволарның аерым исәп-хисаплары кысаларында түгел, ә аерым мәгълүмати ресурс рәвешендә алып барырга кирәк, дип санאיбыз, аның нигезендә һәр махсус хәрби операциядә катнашучы игътибарда булырга тиеш.

«Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы җитәкчесе мәгълүматы буенча, 2025 елда филиалда махсус хәрби операциядә катнашучылар турында мәгълүматларның бердәм системасын кертү планлаштырыла.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 175 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Әлеге мәгълүматны исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Цифрлы үсеш, дәүләт идарәсе, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгына (алга таба - Цифрлы үсеш министрлыгы) системага техник ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре өчен мобиль кушымта эшләү мөмкинлеген карарга тәкъдим итә.

Республикада махсус хәрби операция зонасыннан кайткан махсус хәрби операциядә катнашучыларны реабилитацияләүгә ярдәм итү мәсьәләләренә зур игътибар бирелә.

2024 елның гыйнварыннан «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү үзәге базасында яралану, контузия, гарипләнү нәтиҗәсендә инвалидка әверелгән һәм даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ булган махсус хәрби операциядә катнашучыларга социаль хезмәт күрсәтү бүлеге эшли.

2025 елда бу эшкә Казан, Чаллы, Әлмәт һәм Баулы шәһәрләрендә инвалидларны тернәкләндерү үзәкләре кушылачак. Шул рәвешле, махсус хәрби операциядә катнашучыларны реабилитацияләү өчен 2025 елдан башлап, 282 стационар һәм 130 ярымстационар урын булачак. Кирәкле җиһазларны ремонтлауга һәм сатып алуга, Татарстан Республикасы Рәисе Р. Н.Миңнеханов карары нигезендә, республика бюджетыннан 56,7 млн. сум бүлеп бирелгән.

Хезмәт министрлыгына Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Татарстан Республикасы буенча медик-социаль экспертизаның Баш бюросы», Россия Федерациясе Пенсия һәм Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге, «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы белән берлектә, урыннарда махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә социаль ярдәм, социаль хезмәт күрсәтү һәм социаль тернәкләндерү чаралары комплексын гамәлгә ашыру максатларында, ведомствоара хезмәттәшлекне дәвам итәргә кирәк.

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын эшкә урнаштыру мәсьәләләре**

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил махсус хәрби операциядә катнашучыларның эшкә урнашуына анализ ясады. 2024 елның 18 декабренә мәшгульлек хезмәте органнарына эшкә урнашуда ярдәм сорап 112 кеше мөрәҗәгать иткән, шуларның 73 кешесе эшкә урнаштырылган, 20 кеше укырга җибәрелгән, 19 кеше вакансияләр сайлау процессында. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның 8 гаилә әгъзасы үз эшләрен ачу өчен 145,1 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме алды, шуларның 5се 2024 елда. Хезмәт министрлыгы махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары өчен 24 махсуслаштырылган вакансияләр ярминкәсе үткәрде.

Төзәтү учреждениеләреннән Россия Федерациясе Оборона министрлыгы яисә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә булышлык итүче оешмалар белән контракт төзегән гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, хөкем карарлары юкка чыгарылуга карамастан, эш бирүчеләрнең аларны эшкә теләмичә генә алуларын күрсәтә.

Күрсәтелгән категориядәге затлар белән эшләгәндә хөкем ителү турындагы белешмәләрдә хөкем ителү турында мәгълүмат саклану һәм җинаять эзәрлекләве факты булуы яисә җинаять эзәрлекләвенең туктатылуына, белем, хезмәт күнекмәләре



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 176 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

булмауга бәйле кыенлыклар килеп чыга, карала торган категориядәге затларның кайберләре моңа кадәр беркайчан да эшләмәгән; эшкә урнашырга/укырга теләге дә булмаган.

«Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы социаль координаторларының махсус хәрби операциядә катнашучы һәркем белән аның ихтыяҗлары нигезендә индивидуаль эшләвен билгеләп үтәргә кирәк.

Мәсәлән, «Вагнер» ЧВК сугышчысы, Нурлат районында яшәүче, махсус хәрби операция зонасыннан кайткач, социаль координаторга бизнес белән шөгыльләнү теләге белән мөрәҗәгать иткән. Социаль координатор бизнес-план төзергә, социаль контракт төзергә һәм үз эшен - күчмә шиномонтажны ачарга ярдәм итте.

Әлеге мәсьәләнең актуальлеген исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил, Хезмәт министрлыгына махсус хәрби операциядә катнашучыларга үз эшләрен ачу өчен бер мәртәбә бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү практикасын дәвам итәргә тәкъдим итә.

Вәкаләтле вәкил хәрби хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының хокукларын үтәү мәсьәләләрендә дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук предприятиеләр һәм оешмалар белән тыгыз хезмәттәшлеккә ышаныч белдерә.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 177 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31

# 3-НЧЕ БҮЛЕК. СӘЯСИ ХОКУКЛАРНЫ ҺӘМ ИРЕКЛӘРНЕ ЯКЛАУ

## 3.1. Гражданнарның сайлау хокуклары

Вәкаләтле вәкил гражданнарның сайлау хокукларын тәэмин итүдә һәм яклауда актив катнаша. 2024 ел Татарстан Республикасы өчен ике сәяси әһәмиятле вакыйга белән билгеләп үтелде: Россия Федерациясе Президентын сайлау һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау.

Сайлаулар хакимият һәм җәмгыять арасында мөһим кире элемтә ролен уйный, алар ярдәмендә россиялеләр Россия Федерациясе Конституциясе биргән сайлау хокукларын гамәлгә ашыра һәм илнең, республиканың киләчәк үсеш юнәлешен билгели ала. Бик мөһим, җаваплы сайлау кампанияләре беренче тапкыр көчле геосәяси чакырулар, махсус хәрби операцияләр уздыру зонасында, илнең чик буе районнарында хәрби хәрәкәтләр шартларында узды.

2024 елгы сайлауларны уздыруны оештыруда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең гражданнарның сайлау хокукларын тәэмин итүдә зур тырышлыгын билгеләп үтәргә кирәк. Әлеге хакимият органы тарафыннан чираттагы мәртәбә күрсәтелгән югары дәрәҗәдәге профессионализм һәм сайлауларны оештыруда һәм уздыруда җаваплылык, төрле дәрәҗәләрдә гражданнарның хокукларын бозуны кисәтүгә бәйле күп кенә мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек бирде. Сайлауларның масштаблы булуына карамастан, сайлау хокукларын бозуга кагылышлы мөрәҗәгатьләр саны аз иде, бу сайлау хокукларын яклауның нәтиҗәле гарантияләре системасы булуын күрсәтә.

2024 елның мартында узган Россия Федерациясе Президентын сайлаулар Татарстан Республикасы өчен дә, бөтен ил өчен дә якындагы 6 елга дәүләт яшәеше юнәлешен билгеләгән мөһим сәяси вакыйгаларның берсе булды. Татарстанлылар үз хокукларын 2722 участок комиссиясендә гамәлгә ашыра алды.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты компетенциясенә сайлауларга бәя бирү керми, әмма бу мәсьәләдә Вәкаләтле вәкилнең төп бурычы гражданнарның сайлау хокуклары үтәлешен мониторинглау булды. Шул сәбәпле, сайлауларны уздыру чорында Вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре телефон аша «кайнар элемтә» үткәрделәр, ә Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчеләре республиканың муниципаль берәмлекләрендә «урыннарда» сайлау барышында гражданнарның хокуклары үтәлешен күзәттеләр. Телефон «кайнар элемтәләр»е барышында (2024 елның 15-17 марты һәм 2024 елның 8 сентябре) 47 һәм 53 шалтырату булган. Халыкның сораулары участок сайлау комиссиясе урнашкан урынга, республика территориясендә теркәлмәгән кешеләр өчен тавыш бирү мөмкинлегенә, шулай ук теркәлү урыны буенча түгел, ә булу урыны буенча тавыш бирүгә, өйдә тавыш бирүгә кагылды. Барлык сораулар да «онлайн» режимында хәл ителде, бер генә мөрәҗәгать тә игътибарсыз калмады.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, теркәлү урыны буенча булмаган теләсә кайсы уңайлы сайлау участогында тавыш бирү мөмкинлеге турында халыкка җиткерү мәсьәләсе кала. Кызганычка каршы, «кайнар элемтәләр» вакытында мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе сайлау участогын үзгәртү турында Дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза бирү мөмкинлеге турында хәбәрдар булмаган. Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 178 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

белән берлектә сайлаулар алдыннан сайлау участогын үзгәртү мөмкинлеге турында гражданнарга мәгълүмат бирү эшен көчәйтергә тәкъдим итәбез.

Беренче чиратта сайлау хокукларын үтәү мониторингы төрле тормыш шартлары буенча сайлаулар уздырыла торган урыннарга шәхсән бару мөмкинлеге булмаган гражданнар өчен гамәлгә ашырылды. Бу Вәкаләтле вәкил өчен бик мөһим бурыч булып тора, чөнки илнең һәр гражданы өчен сайлаулардан файдалану мөмкинлеге – конституциячел хокукларны тулы күләмдә гамәлгә ашыру гарантиясе. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең инвалид гражданнарның сайлау хокукларын тәэмин итү буенча эш төркеме составына керә. Инвалидларның сайлау хокукларын гамәлгә ашыру проблемасын хәл итүдә сизелерлек уңышлар арасында тавыш бирү участокларын беренче катларга күчерүне, шулай ук алар урнашкан биналарны пандуслар белән тәэмин итүне искә алырга кирәк.

2024 елның 1 гыйнварына республикада 268,4 мең инвалид граждан яши иде, шуларның 39,0 меңе - күрү, ишетү, терәк-хәрәкәт аппараты буенча инвалид сайлаучылар. Аз хәрәкәтләнүче сайлаучыларга тавыш бирү уңайлылыгы өчен 1 090 сайлау участогы махсус кабиналар белән җиһазландырылган. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясендә ГЛОНАСС+112 системасы һәм «Бөтенроссия чукраклар җәмгыятенең» республика бүлеге белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләсе каралды: ишетү буенча мөмкинлекләре чикләнгән сайлаучылар кирәк булганда ишарәләр телен белгән тәрҗемәче ярдәменнән «WhatsApp» мобиль кушымтасындагы махсус номерга видео шалтырату аша файдалана алдылар.

Күрү сәләте буенча инвалид булган сайлаучыларга ярдәм йөзеннән Татарстан Республикасында сайлау участоклары махсус трафаретлар белән тәэмин ителде. Алар сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән татарстанлыларга Брайль шрифтын кулланып эшләнгән бюллетеньнәрне мөстәкыйль тутырырга булыштылар. Республиканың сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус китапханәсендә шундый 2700дән артык трафарет ясалды. Шулай ук республика сайлау участокларының мәгълүмат стендларында махсус брошюралар урнаштырылды. Аларда начар күрүче сайлаучыларга уңайлы булсын өчен Россия Президенты постына кандидатлар турында эре шрифт һәм Брайль шрифты белән басылган мәгълүмат бар иде. Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән сайлаучылар өйләрендә тавыш бирү өчен участок сайлау комиссияләренә гариза белән мөрәҗәгать итә алганнар. Моны язма рәвештә дә, телдән дә эшләргә мөмкин иде. Мондый мөрәҗәгать кергән очракта участок сайлау комиссиясе аз хәрәкәтләнүчене сайлаучыга өйдә тавыш бирү мөмкинлеген оештырды.

Үткәрелгән мониторинг нигезендә сайлау участокларыннан файдалану мөмкинлеге:

- беренче катларда республика сайлау участокларының 93,5% ы урнашкан;
- икенче катларда 176 сайлау участогы урнашкан, бу республика сайлау участокларының гомуми санының 6,5% ын тәшкил итә.

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җитәкчеләренә сайлау кампанияләре кысаларында эшләүче барлык сайлау участокларын беренче катларга күчерү һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән гражданнар өчен «уңайлы мохит» оештыру мөмкинлеген карарга киңәш итәбез.

Сайлауларны үткәрү чорында Вәкаләтле вәкил, Аппарат хезмәткәрләре һәм җәмәгатьчелек ярдәмчеләре район үзәк хастаханәләрендә, Россия Федерациясе



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 179 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең тикшерү изоляторларында (№1,2,3,4,5), Эчке эшләр министрлыгының вакытлыча тоту изоляторларында оештырылган 50гә якын сайлау участогында булдылар, тавыш бирү барышын күзәтүгә, сайлау комиссияләре әгъзалары эшенә, шул исәптән, сайлаучыларга бюллетеньләр бирүгә, сайлаулар вакытында гражданнарның документларын тикшерүгә һәм башка процессуаль этапларга аерым игътибар бирделәр. Хастаханәләрдә, санаторийларда, тикшерү изоляторларында, тимер юл вокзалында һәм аэропортта 45 өстәмә участок ачылды.

Россия Президентын сайлауның беренче көнендә Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 3 нче төзәтү колониясендә (Питрәч муниципаль районы) тикшерүдә булганнарның сайлау хокукларын үтәү мониторингын үткәрде. Биредә тикшерү астында булган 75 кеше үз ихтыярын белдерде, ә бу төзәтү учреждениесендә сайларга хокукы булганнарның 100% ы.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка сайлаулар кысаларында, Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 1 нче тикшерү изоляторында урнашкан участок сайлау комиссиясендә булды, анда хөкем карары законлы көченә кермәгән барлык шикләнелүчеләр, гаепләнүчеләр тавыш бирә ала иде. 1200 гә якын кеше үз гражданлык позициясен белдерде, аларның һәркайсының хокуклары тулысынча үтәлде һәм хокук бозулар ачыкланмады.

Сайлауларны үткәрүнең үтә күренмәле һәм законлы булуын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы каршындагы Иҗтимагый күзәтү үзәгендә тавыш бирүнең онлайн-трансляциясе оештырылды, анда Вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре сайлауларны үткәрү чорында сайлау хокукларын яклау турындагы законнар таләпләренең үтәлешен күзәттеләр. Сыйфатлы сурәт, кадрларда сайлау участокларының еш алмашынуы, киң форматлы экран һәм төгәл оештыру республика буенча сайлау участокларын игътибар белән күзәтергә мөмкинлек бирде. Күзәтү барышында Казан шәһәрендә һәм Түбән Кама муниципаль районында яшерен тавыш бирүгә конституциячел хокук бозылган ике сайлау участогы ачыкланды, чөнки камераларда тавыш бирү кабиналары эчендә булган хәлләрне күрергә мөмкин иде. Сайлау участокларының адресларын күрсәтеп, мәгълүмат һәм раслый торган фотоматериаллар кичекмәстән Үзәк сайлау комиссиясе адресына җибәрелде, әлеге хокук бозу оператив рәвештә төзәтелде.

«Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалы 12 сәгатьлек «Бөтен гаилә белән сайлауларга» гаилә телемарафонын ачып, сайлауларның гаилә өчен әһәмиятен ассызыклады, анда Вәкаләтле вәкил оныгы Булат белән Сабурскийлар гаиләсенең традицияләре, проблемаларны һәм авырлыкларны бергәләп хәл итү, тормышның иң шатлыклы һәм күңелле мизгелләрен бергә кичерү турында сөйләштеләр.«Яңалыклар»ның махсус чыгарылышлары, концерт программалары, шулай ук җиңүчеләргә Lada Vesta автомобильләреннән ачкычлар бирелгән «Бөтен гаилә белән сайлауларга» бәйгесе бу көннәрне барыбыз өчен дә истә калырлык итте, татарстанлыларның гаилә җылысы белән берләштерде. Бу стратегия җәлеп итүчәнлекне арттырып кына калмый, ә татарстанлыларның дәүләт һәм республика өчен мөһим карарлар кабул итү процедурасына югары дәрәҗәдә җәлеп ителүенә дә ярдәм итә.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 180 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан сайлау комиссияләренең эш йомгаклары буенча узып баручы елда сайлау процессының ачыклыгын һәм легитимлыгын ышанычлы тәэмин итеп булды, сайлаучыларның сайлаулар институтына ышанычы артты. Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе рәисе сүзләренчә, 2012 елда ышаныч дәрәҗәсе 44% тәшкил итсә, 2018 елда – 60%, 2024 елда Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге мәгълүматлары буенча, Россия Президенты сайлауларында бу дәрәҗә 83% ка җиткән. Республика сайлау комиссияләре әгъзаларының югары дәрәҗәдәге һөнәри әзерлеге 2024 елгы сайлауларны бернинди җитди кисәтүләрсез, шикаятьләрсез һәм конфликтларсыз уздырырга мөмкинлек бирде.

2025 елның сентябрендә республиканың төп сайлаулары – Татарстан Республикасы рәисен сайлаулар узачак. Шулай ук муниципаль районнарда җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарына 7500 мең депутат сайланачак. Республика Үзәк сайлау комиссиясе утырышында Рәис сайлауларының календарь планы расланды, муниципаль сайлауларда сайлау округларының чикләрен билгеләү буенча эш башланды.

Ышанам ки, Татарстан Республикасы Рәисен сайлаулар гражданлыкның югары дәрәҗәсен күрсәтеп, оешкан төстә узачак.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 181 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31

# 4-НЧЕ БҮЛЕК. СОЦИАЛЬ ҺӘМ ИКЪТИСАДЫЙ ХОКУКЛАРНЫ ЯКЛАУ

## 4.1. Хезмәткә хокук

2024 ел Россия хезмәт кануннары өчен үзгәрешләр елы булды. Хезмәт шартларын сизелерлек яхшыртуга һәм хезмәткәрләрнең хокукларын яклауга ярдәм иткән үзгәрешләр кабул ителде. Узган елгы яңалыклар хезмәт мөнәсәбәтләренең барлык яклары өчен гаделрәк, үтә күренмәле һәм яхшы шартлар тудырырга ярдәм итә.

Эшләүче гражданнар өчен 22.04.2024 № 91-ФЗ Федераль закон кабул ителү мөһим үзгәреш булды, ул эштән тыш сәгатьләр өчен түләүне исәпләү кагыйдәләрен яңартты. 2024 елдан эштән тыш түләүләр исәбенә оклад кына түгел, ә премияләр, хезмәт шартлары өчен өстәмә түләүләр һәм башка компенсация һәм стимуллаштыручы түләүләр дә кертелә. Бу үзгәрешләр хезмәт хакы төрле состав өлешләреннән торган хезмәткәрләр өчен өстәмә эш вакытын гаделрәк исәпләүне тәэмин итә.

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 236 нчы маддәсенең беренче өлешенә шулай ук үзгәрешләр кертелде, алар нигезендә эш бирүчедән процентлар (акчалата компенсация) түләтелергә тиеш, бу хезмәткәргә тиешле түләүләр аңа үз вакытында исәпләнмәгән, ә суд карары белән хезмәткәрнең аларны алу хокукы танылган очракта. Элек мондый компенсацияне эш бирүче хезмәткәргә тиешле исәпләнгән, әмма вакытында түләнмәгән суммалар буенча гына түләргә тиеш булган.

Дәүләт тарафыннан күрелә торган чаралар гражданнарның хезмәт мөнәсәбәтләрен яклау өлкәсендәге хәлләргә уңай йогынты ясый. Соңгы ике елда хезмәткә хокукны яклау мәсьәләләре буенча Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьләр саны кимү тенденциясе дәвам итә. Карала торган категориядәге шикаятьләр санының кимүе эшкә урнашу өлкәсендәге вәзгыятьнең яхшыруын күрсәтә торган рәсми статистика белән бәйле.

Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматларына караганда, 2024 елның июль – сентябрь айларында Татарстан Республикасында 15 яшьтән өлкәнрәк эшче көчләр саны уртача 2 075, 3 мең кеше тәшкил иткән, шуларның 2 038, 5 меңе икътисадта мәшгуль булган һәм 36,8 мең кешенең, ягъни эшче көчләр санының 1,8% нан, эшләре булмаган, әмма аны актив эзләгәннәр. Халыкның мәшгульлек дәрәҗәсе 62,4% тәшкил итә. Теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе республикадагы эшче көчләр санының 0,16% тәшкил итә.

### Хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләүгә хокукларын яклау

Татарстан Республикасы Идел буе федераль округы төбәкләре арасында хезмәт хакы дәрәҗәсе буенча беренче урында тора. 2024 елның гыйнвар-октябрь айларында Татарстан Республикасында уртача хезмәт хакы 2023 елның шушы чоры белән чагыштырганда 21% ка артты һәм 72 009,1 сум тәшкил итте.

Әмма тармаклар арасында хезмәт өчен түләүнең тармак дифференциациясе элеккечә саклана, ул 2,7 тапкырга кадәр җитә.

Кешеләрне икътисадның реаль секторына җәлеп итү зарурлыгы шартларында торак-коммуналь хуҗалык, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм җәмәгать туклануы, урман хуҗалыгы, мәгариф кебек тармакларда хезмәт хакын күтәрү мәсьәләсе беркайчан да булмаганча актуаль булып кала. Бигрәк тә үзмәшгульләрнең



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 182 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

кереме арту фонында, Россия Хезмәт министрлыгы мәгълүматлары буенча, республикада ул 84,4 мең сум тәшкил итә.

2024 елның 1 гыйнварыннан Россиядә хезмәт өчен түләүнең минималь күләме 18,5% ка – 19 242 сумга кадәр арткан, шуңа бәйле рәвештә хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән түбән булмаган хезмәт хакын тәэмин итү мәсьәләсе актуаль булып кала.

2024 елда республикада минималь хезмәт хакыннан түбәнрәк хезмәт хакы түләүче оешмалар саны кимү тенденциясе күзәтелде (822 дән 667 оешмага кадәр).

Муниципаль берәмлекләрнең һәм шәһәр округларының территориаль ведомствоара комиссияләре тарафыннан 2 852 оешма каралды, хезмәт хакы минималь хезмәт хакыннан түбәнрәк түләнгән 148 оешма ачыкланды (503 хезмәткәр). 145 оешмада башкарылган эш нәтиҗәләре буенча 499 хезмәткәр 1 772,21 мең сум күләмендә өстәмә хезмәт хакы алган.

Комиссия эшчәнлеген анализлау нәтиҗәләре буенча 9 муниципаль берәмлектә (Әгерҗе, Балтач, Минзәлә, Мөслим, Яңа Чишмә, Питрәч, Теләче, Чирмешән, Чистай муниципаль районнары һәм Яр Чаллы шәһәре) хезмәт хакы законда билгеләнгән минималь күләмнән түбәнрәк булган оешмаларда тулы булмаган эш белән тәэмин ителмәү дәрәҗәсен киметү бурычы хәл ителмәгән.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил республика территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмаларда хезмәт хакы буенча бурычларга бәйле вәзгыятькә анализ ясады.

Министрлыклардан һәм ведомстволардан алынган мәгълүматны анализлаудан күренгәнчә, эш бирүчеләрнең хезмәткәрләр алдындагы гомуми бурычы 01.12.2024 елга 30,6% ка кимегән (01.01.2024 - 89 242,05 млн.сум, 01.12.2024 – 61 954, 33 млн. сум). Шул ук вакытта 2024 елның 1 мартына бурыч күләменең 26,07% ка артуы күзәтелгән (01.03.2024 – 112 509,35 млн.сум).

2024 елның 11 аенда хисап даталарында (һәр айның беренче саны) бурычлы оешмалар саны 17 дән 32 гә кадәр тәшкил итте (шул ук мәгълүматлар буенча 2023 елда - 34 тән 74 кә кадәр, 2022 елда – 45 тән 61 кә кадәр, 2021 елда – 70 тән 112 гә кадәр, 2020 елда – 81 дән 159 га кадәр). Шулай ук билгеләп үтик, ел башында 1415 хезмәткәргә хезмәт хакы буенча бурыч булса, ел ахырына аларның саны 53,3% ка (661 хезмәткәр) кимегән.

Гомумән алганда, узган еллар белән чагыштырганда бурыч суммасында да, ул булган хезмәткәрләр санында да бурычның кимү тенденциясен билгеләп үтми булмый.

Шул ук вакытта хезмәт хакын түләмәү мәсьәләләре Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итү сәбәбе булып тора иде. Әлеге категориядәге мөрәҗәгатьләр, Вәкаләтле вәкилнең хокукый позициясен бәян итеп, прокуратура органнарына, Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясенә юлланды. Әлеге мөрәҗәгатьләр хезмәт хакы буенча бурычлар тулысынча түләнгәнче безнең контрольдә калды.

Хезмәт хакын түләмәүгә шикаятьләр шулай ук «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» кире элемтә платформасы аша Вәкаләтле вәкил адресына да килгән.

Вәкаләтле вәкил адресына гражданка З.дан «ПРОЕКТСТРОЙ» ҖЧҖ эштән киткәндә аңа хезмәт хакы түләнмәве турында хәбәр килгән. Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен тикшерүне оештыру һәм чаралар күрү өчен Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе җитәкчесе вазифаларын башкаручы адресына мөрәҗәгать итте. Безнең хатны карау йомгаклары буенча



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 183 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе тарафыннан «ПРОЕКТСТРОЙ» ҖЧҖ адресына Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 236 нчы маддәсе нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куелмау һәм мөрәҗәгать итүчегә хезмәт хакы буенча бурычларны түләү, эштән азат ителгәндә соңгы исәп-хисапны башкару, шул исәптән тиешле суммаларны түләүне тоткарлаган өчен акчалата компенсация түләү буенча чаралар күрү турында кисәтү игълан ителде.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2024 елның 12 ае эчендә прокурорлар тарафыннан хезмәткә түләү өлкәсендә 3282 хокук бозу ачыкланган, 373 протест белдерелгән, 285 дәгъва гаризасы җибәрелгән, 896 тәкъдим кертелгән, алар буенча 825 вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылган, прокурорлар карарлары буенча 324 зат административ җаваплылыкка тартылган, Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 37 нче маддәсе 2 өлешенең 2 пункты тәртибендә 27 зат кисәтелгән.

## Эштән азат ителгәндә хезмәткәрләрнең хокукларын яклау

Хисап елында Вәкаләтле вәкил адресына шулай ук гражданнардан эштән китәргә мәҗбүр итү, хезмәт килешүен өзгәндә законнарны бозу, эштән китү белән килешмәү, шуңа нигезсез эштән читләштерү һәм вазыйфаларын яңадан торгызуда ярдәм итүне сорап шикаятьләр керде.

Контроль-күзәтчелек органнарына мондый мөрәҗәгатьләрне тикшерүне уздыруны сорап мөрәҗәгать итү белән беррәттән, Вәкаләтле вәкил хокук бозулар булган оешмаларның җитәкчеләренә аларны оператив рәвештә бетерү максатында, шул исәптән оешмага барып мөрәҗәгать итү шартларын тикшерү юлы белән дә үз позициясен белдерде.

Агымдагы елның августында Вәкаләтле вәкилгә III нче төркем инвалидтан мөрәҗәгать килде, ул Казан шәһәренең дәүләт медицина оешмаларының берсе җитәкчелеге тарафыннан аның хокукларын кысу очраклары турында хәбәр итте. Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче үзенә чираттагы еллар графигы нигезендә еллык түләүле чираттагы ял бирүдән баш тарту турында хәбәр итте.

Вәкаләтле вәкил кушуы буенча Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкилләре белән берлектә әлеге учреждениегә чыкты.

Мөрәҗәгатьне карау кысаларында мөрәҗәгать итүченең дәлилләре өлешчә расланды. Без ачыклаганча, чираттагы яллар графигында каралган срокларда гариза бирүчегә чираттагы ял бирелмәгән, шул ук вакытта гариза бирүче ялы башлану датасын күчерү турында мөрәҗәгать итмәгән. Моннан тыш, гариза бирүче, инвалид буларак, 30 көнлек ял алырга хокуклы булган, әмма чираттагы яллар графигында бары тик 28 көн генә күрсәтелгән.

Урынга барып тикшерү нәтиҗәсендә без өстәмә эше буенча хезмәт хакын үзвакытында түләмәүләрпен ачыкладык, ( аена бер тапкыр гына түләнгән).

Мөрәҗәгатьне карау йомгаклары буенча Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры адресына, мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозуга юл куйган гаепле затларны җаваплылыкка тарту турында үтенеч хаты җибәрде. Шулай ук учреждение хезмәткәрләренең хокукларын бозуга юл куймау буенча чаралар күрергә тәкъдим ителде. Вәкаләтле вәкилнең үтенече канәгатьләндерелде, гаепле зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 184 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Тикшерү чараларыннан тыш, безнең тарафтан Казанда да, республиканың башка муниципаль берәмлекләрендә дә хокукый консультацияләр бирү, хезмәт законнары мәсьәләләре буенча киң эш алып барыла, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдалану юлы белән дә.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чаралары материалларына һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хокукларын бозу турында хәбәр бирә торган башка чыганакларга мониторинг ясады.

Массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнарның хезмәт хокукларын үтәү мәсьәләләре буенча бастырылган мәгълүматка үткәрелгән анализдан «ВБ Восток» (ВАЙЛДБЕРРИЗ) ҖЧҖ эш бирүчесе тарафыннан матди санкцияләр куллану, тикшерүләр үткәрү, эш вакыты графигы һ. б. өлешендә хезмәт хокукларының бозылуы күренде.

Күрсәтелгән оешмаларның гражданнарның хезмәт хокукларын үтәвен һәрьяклап өйрәнү максатларында, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Прокуратурасына һәм Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясенә, күрсәтелгән оешмага гражданнардан кергән шикаятьләр саны турында хат җибәрде.

2024 елда (26.11.2024) Яшел Үзән шәһәр прокуратурасы тарафыннан «ВБ Восток» ҖЧҖ хезмәткәрләренең хезмәт хокукларын бозу мәсьәләләре буенча гражданнардан 17 мөрәҗәгать каралган.

Мөрәҗәгатьләрне карау барышында «ВБ Восток» ҖЧҖнең Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 57 нче маддәсенең 11 пунктын бозып, 20 сәгатьтән иртәнге 8 гә кадәр эш режимы каралган хезмәткәрләрнең хезмәт килешүләрендә төнге вакытта эшләгән өчен компенсация түләүләре язылмаган; Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 103 нче маддәсе 2,4 пунктлары таләпләрен бозып, «ВБ Восток» ҖЧҖ тикшерү барышында смена графигы бирелмәгән; оешма тарафыннан хезмәт килешүләре штат расписаниесендә каралганнан күбрәк хезмәткәрләр белән төзелгән (тапшырылган штат расписаниесе буенча штат саны – 20216 берәмлек, факттагы саны бирелгән белешмә буенча – 23301 кеше һ.б.). Яшел Үзән шәһәре прокуратурасы барлык ачыкланган хокук бозулар буенча прокурор чаралары күрде. Ачыкланган хокук бозулар бетерелде, хокук бозуларны киләчәктә булдырмау чаралары күрелде.

## Мәҗбүри күченүчеләрнең хезмәт хокукларын яклау

Вәкаләтле вәкилнең мониторинг эшчәнлеге шулай ук гражданнарның аерым категорияләренең - хәрби хәрәкәтләр зоналарыннан эвакуацияләнгән затларның хезмәт хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырылды.

2025 елның 8 гыйнварына вакытлыча урнаштыру пунктларында («Ливадия» шифаханәсендә, «Кварт» кунакханәсендә, «Экспресс», «Икенче йорт» хостелларында, «Жемчужина», «Васильевский», «Санта» шифаханәләрендә) 319 кеше яши, шуларның 217се эшкә сәләтле гражданнар.

Узган елда Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре һәм Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесе Г. Г. Балафендиева эвакуацияләнгән затларны вакытлыча урнаштыру пунктларына даими килеп йөрделәр. кабул итү барышында мөрәҗәгать итүчеләр нигездә эшкә урнашу, хезмәт стажын раслау, пенсия белән тәэмин итү һәм башка мәсьәләләрне күтәрделәр.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 185 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Безнең ярдәм белән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган 9 гражданны эшкә урнаштыруга ирешелде.

Гомумән алганда, гражданнарны вакытлыча урнаштыру пунктларыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә 236 кеше мөрәҗәгать иткән. Хисап көненә хезмәт эшчәнлеген 224 кеше башкара.

Югалган документларны торгызу мәсьәләсе иң актуаль булып кала бирә. Кызганычка каршы, гражданнар эшләгән предприятие документлары белән архивлар юк ителгән, архивларның бер өлеше Украина территориясенә чыгарылган. Кешеләр стаж, хезмәт хакы, уку урыны, белем алу һ. б. турындагы мәгълүматларны раслый алмыйлар.

Әлеге мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм итү өчен безнең тарафтан яңа төбәкләрнең Кеше хокуклары буенча төбәк вәкаләтле вәкилләре белән хезмәттәшлек гамәлгә ашырылды.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил адресына граждан И. дән аның хезмәт эшчәнлеген, хезмәт стажын раслый торган белешмәләр, хезмәт хакы турында белешмәләр, шулай ук эшләрнең үзенчәлекле характерын ачыклый торган белешмәләр алуда ярдәм күрсәтү турында мөрәҗәгать керде. Вәкаләтле вәкил Донецк Халык Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына хат юллады. Донецк Халык Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Донецк Халык Республикасы күмер һәм энергетика министрлыгы мөрәҗәгате нигезендә мөрәҗәгать итүче адресына аның «Октябрьский рудник» шахтасында эшләү чоры өчен архив документлары һәм «Шахта им. А.Ф. Засядько» предприятиесендә эш хакы турында белешмә җибәрелде.

**Гражданнарның имин хезмәт шартларына хокукларын яклау**

Хокук яклау эшчәнлегендә республикада производствода имгәнүләр белән бәйле вәзгыять Вәкаләтле вәкилне аеруча борчый. Эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау турындагы законнарны үтәмәве хезмәткәрләрнең имин хезмәткә хокукларын бозуга китерә.

Узган елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан гражданнарның хезмәтне саклау шартларын бозу турындагы мөрәҗәгатьләре буенча чаралар күрелде.

Вәкаләтле вәкил Аппаратына «Татвторчермет» ҖЧҖендә булган бәхетсезлек очрагы турында, аңа бәхетсезлек очрагы турында акт бирүдән баш тарту турында граждан Б.мөрәҗәгать итте.

Казан шәһәре Идел буе районы прокуратурасы Вәкаләтле вәкил инициативасы белән әлеге мөрәҗәгать буенча тикшерү оештырды, аның барышында бәхетсезлек очрагының сәбәпләре ачыкланды, болар - зыян күрүчене белгечлеге буенча файдаланмау, хезмәткәрне хезмәт функциясе каралмаган эшкә кертү; бүлекчә җитәкчеләре һәм белгечләре тарафыннан эшләрнең барышын, хезмәт дисциплинасының үтәлешен контрольдә тотмау, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 214 нче маддәсе таләпләрен бозу; хезмәткәрнең Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 215 нче маддәсе таләпләрен бозып, индивидуаль яклау чараларын кулланмавы.

Ачыкланган хокук бозулар нигезендә Казан шәһәренең Идел буе районы прокуратурасы тарафыннан «Татвторчермет» ҖЧҖ тарафыннан РФ КоАП 5.27.1



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 186 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

маддәсенең 4 өлеше буенча административ хокук бозу турында эш кузгату турында карар чыгарылган. Гаепле вазыйфаи зат дисциплинар административ җаваплылыкка тартылды. Шулай ук прокуратура органы мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә производствода бәхетсезлек очрагы нәтиҗәсендә китерелгән мораль зыянны түләтү турында судка дәгъва гаризасы җибәргән.

Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматлары буенча, 2024 елда (2024 елның 20 декабренә) Татарстан Республикасы производстволарында 135 бәхетсезлек очрагы булган, шуларның 35е үлем белән тәмамланган.

Чистай районында (1 дән 3 кә кадәр), Яшел Үзән районында (0 дән 3 кә кадәр), Мамадыш һәм Саба районнарында (0 дән 2 гә кадәр) 2 мәртәбә, Алабуга районында (5 тән 9 га кадәр) 1,8 мәртәбә, Алексеевск районында (2 дән 3 гә кадәр) 1,5 мәртәбә, Яр Чаллы шәһәрендә (26 дан 34 кә кадәр) 1,3 мәртәбә имгәнүләр арту борчу тудыра.

Хисап елының декабрендә Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе советының «Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясенең һәм аның әгъза оешмаларының хәзерге шартларда хокук яклау эше» утырышында чыгыш ясады, анда гражданнарның хезмәт хокукларын үтәүнең актуаль мәсьәләләрен, шул исәптән хезмәтне саклау мәсьәләләрен билгеләп үтте. Утырыш кысасында Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе тарафыннан хезмәтне саклау өлкәсендәге төп хокук бозулар арасында җаваплы затларның эшне имин алып баруын тикшереп торуның җитәрлек булмавы, хезмәтне саклау белән идарә итүнең нәтиҗәле системаларының булмавы, һөнәри куркынычларны бәяләүне үткәрмәү, хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне вакытында укыту һәм күрсәтмәләр бирүнең җитәрлек булмавы, сыйфатлы индивидуаль яклау чаралары белән тәэмин итүнең җитәрлек булмавы һ. б. турында мәгълүмат тәкъдим ителде.

Эш бирүчеләрнең хезмәтне саклау турындагы законнарны үтәмәве хезмәткәрләрнең имин хезмәткә хокукларын бозуга китерә. Шуның нәтиҗәсендә кайбер предприятиеләрдә («Түбән Кама нефтехим», «Алексеевскдорстрой», «Челтәр компаниясе» филиалларында) берничә мәртәбә бәхетсезлек очраклары була.

Эшчеләрнең иминлеген тәэмин итүдә хезмәтне саклау комитетларына (комиссияләргә) зур роль бирелә, алар өстенлекле нигездә төзеләләр һәм оешмаларда хезмәтне саклау идарәсендә катнашалар. Әлеге комитетлар (комиссияләр) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 224 нче маддәсе нигезендә эш бирүче инициативасы һәм (яисә) хезмәткәрләр яки аларның вәкаләтле вәкиллекле органы инициативасы буенча төзелә.

Әмма эш бирүче тарафыннан мондый инициатива күрсәтелмәскә дә мөмкин, ә хезмәткәрләрнең тәкъдиме - ишетелмәскә дә мөмкин. Законда һәм башка норматив хокукый актларда, шулай ук эш бирүче хезмәткәрләрнең яки аларның вәкаләтле органының хезмәтне саклау комитетын (комиссиясен) төзү турындагы тәкъдимен карарга тиеш булган вакытлар җайга салынмаган. Шуңа бәйле рәвештә республика территориясендә эшләүче оешмаларга әлеге мәсьәләләрне локаль актта һәм (яисә) коллектив шартнамәләрдә җайга салырга тәкъдим итәбез.

Муниципаль районнарның башкарма комитетлары каршында төзелгән хезмәтне саклау буенча Координация советларына даими нигездә күрсәтелгән комитетларның эшчәнлегенә мониторинг уздырырга, комитетның (комиссияләрнең) оешмаларда булмау сәбәпләрен анализларга, эш бирүченең хезмәтне саклау



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 187 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

комитетын (комиссиясен) төзүдән баш тарту фактлары ачыкланганда, хезмәткәрләрдән килгән гариза булганда әлеге очракларны утырышларда тикшерергә тәкъдим итәбез.

Икътисадның иң имгәнү куркынычы булган тармакларының берсе -төзелеш тармагы. 2024 елда (23.12.2024) төзелеш тармагында 18 бәхетсезлек очрагы булган.

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында хезмәтне саклау буенча ведомствоара эш төркеме составына керә. Эшче төркем утырышларында төзелеш мәйданчыкларында булган бәхетсезлек очраклары карала, җитәкчеләрнең килеп чыккан бәхетсезлек очрагы сәбәпләре һәм мондый хәлләрне булдырмау буенча башкарылган профилактик эшләр турында хисаплары тыңлана.

2024 елның 15 ноябрендә ведомствоара эш төркеме утырышында «Казметрострой» АҖ, «АВИС» ҖЧҖ, «Суварстроит» ҖЧҖ, «Бест СТРОЙ» ҖЧҖ, «Чаллы МУС-2 ТСТМ» ҖЧҖ, «ЭнергоИнжиниринг» ҖЧҖ, «Легион» ҖЧҖ, «СтройЭкспо» ҖЧҖ вәкилләре тыңланды. Аларда бәхетсезлек очраклары теркәлгән. Утырыш йомгаклары буенча югарыда аталган оешмаларның җитәкчеләренә эш бирүче тарафыннан хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту чараларын финанслау турында хисап тапшырырга тәкъдим ителде (РФ Хезмәт кодексының продукция (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүгә чыгымнар суммасының кимендә 0,2% ы үтәлүен раслап); бәхетсезлек очракларына китергән хезмәтне саклау таләпләрен бозуларны бетерү буенча чаралар исемлеге; оешмада һөнәри куркынычларны һәм хезмәтне саклау системасын бәяләүне яңадан карау турындагы мәгълүмат соралды. Үзеннән-үзе көйләүле оешмаларга - «Татарстанның төзелеш оешмалары берләшмәсе» Ассоциациясе, «ТР Төзүчеләр берлеге» һәм «Профессиональ төзүчеләр берлеге»нә төзелеш тармагында бәхетсезлек очракларына юл куйган оешмалар белән тиешле эш алып барырга, аларда производствода имгәнү очракларын булдырмау өчен профилактика эшен көчәйтергә кушылды.

Бәхетсезлек очракларына юл куймау максатларында, ел башыннан, үз-үзләрен көйләүче оешмалар вәкилләре тарафыннан 2 846 тикшерү уздырылган, аларның нәтиҗәләре буенча 992 тапкыр дисциплинар йогынты чаралары кулланылган. ТР дәүләт Төзелеш күзәтчелеге инспекциясе ел башыннан бирле административ җаваплылык турында 184 карар чыгарган. Гомумән алганда, быел ведомство белгечләре төзелеш мәйданчыкларында 1 692 тапкыр булганнар. Баш инвестиция-төзелеш идарәсе гыйнвардан 778 контроль-күзәтчелек чарасы уздырган.

Әлеге эшне камилләштерү максатларында, Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына бәхетсезлек очраклары булган оешмаларда ведомствоара эш төркеменең күчмә утырышларын оештырырга тәкъдим итә.

Вәзгыятьне мониторинглау һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә хокук яклау чараларын күрү буенча эш Вәкаләтле вәкил өстенлекләрендә кала, чөнки күзәтчелек һәм контрольлек итүче ведомстволар, статистика органнары белешмәләре барлык компетентлы структураларның көчләрен берләштерүне һәм аларны хәл итүгә комплекслы якын килүне таләп итә торган хезмәт хокукларын үтәүгә бәйле проблемаларның саклануын дәлилли.

## 4.2. Торакка хокук



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 188 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Хәзерге этапта торак тармагы республикабыз гражданнарының тормыш сыйфатының иң мөһим күрсәткечләреннән берсе булып тора.

Торак фондының торышы һәм гражданнарның төрле категорияләре өчен һәркем ала алырлык һәм уңайлы торакның булуы илнең социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсен, халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм җәмгыятьтәге социаль климатны ачык чагылдыра. Торак шартларын яхшырту гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрүдә төп күрсәткечләрнең берсе, дәүләтнең сәяси һәм икътисадый тотрыклылыгының алшарты булып тора.

Торак сатып алу яки аны төзү күпчелек гражданнарның мөстәкыйль сайлавы булып тора, әмма дәүләтнең һәм җирле үзидарә органнарының роле торак төзелешен үстерүгә ярдәм итүдән гыйбарәт.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматы буенча (алга таба – Төзелеш министрлыгы), республикада 2024 елда 3.452, 7 мең кв.метр торак файдалануга тапшырылган. Социаль ипотека программасы кысаларында узган елда гомуми мәйданы 161,8 мең кв. метр булган 59 йорт файдалануга тапшырылган.

2024 елда Ерак Төньяк районнарыннан киткән 2 гражданның, ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан 627 кешенең, 84 яшь һәм 28 күп балалы гаиләнең торак шартлары яхшыртылган.

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның торак мәсьәләсен хәл итү өчен, 2024 елның февралендә Татарстан Республикасында әлеге категория гражданнарга уңайлыклары булган, милеккә торак урын сатып алуга акча бирү яисә килешү буенча торак урын сатып алуга бирелгән кредит (заем) бирү рәвешендә өстәмә яклау кертелде.

Түләү хокукы торак урын сатып алуга исемле документ – сертификат белән раслана. Гражданнарны яклау өчен акчалар, әгәр сүз ипотеканы түләү турында барса, шунда ук торак урыннарын сатучыларның яки кредит оешмаларының счетларына җибәрелә.

2024 елның 28 декабрендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Мәгариф министрлыгы) узган ел өчен ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга торак сатып алуга 6 сертификат тапшырды.

Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының планлы эше гражданнарның торак проблемаларын хәл итүгә ярдәм итә, бу хакта әлеге тематика буенча Вәкаләтле вәкил адресына килә торган мөрәҗәгатьләр санының кимүе дәлилли. 2024 елда Вәкаләтле вәкил адресына 514 мөрәҗәгать кергән, бу 2023 ел белән чагыштырганда 10% ка кимрәк. Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкил Аппаратына керә торган мөрәҗәгатьләрне анализлау конкрет һәм аеруча әһәмиятле проблемаларны ачыкларга мөмкинлек бирә.

Болар - гражданнарның социаль якланмаган категорияләрен торак белән тәэмин итү, торак урыннарны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортларны авария хәлендәге һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану, авария хәлендәге торак фондыннан күчерү, вакытлыча яшәү өчен маневр фонды бирү, индивидуаль торак йортлар төзегәндә гражданнарның хокукларын бозу, торак йортларга агымдагы һәм капиталь ремонт ясау, коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктатып тору тәртибен бозу, шулай ук коммуналь һәм торак хезмәтләрен тиешенчә күрсәтмәү.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 189 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Проблемалы мәсьәләләрне оператив хәл итү өчен гражданнар «Халык контроле» системасын актив кулланалар. 2024 елда «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына «Торак-коммуналь хуҗалык» юнәлеше буенча түбәндәге категорияләр буенча 8954 хәбәрнамә кергән: «Йортны карап тоту» - 5493 хәбәрнамә, «Коммуналь хезмәтләр» - 2 351 һәм «Йортка агымдагы ремонт» - 995, «Капиталь ремонт» - 113, «Торак-коммуналь хуҗалыгы» - 2 мөрәҗәгать. 2024 ел ахырына 7 818 мөрәҗәгать хәл ителде.

Гражданнарның торак хокукларын һәм гражданнарның ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләре Вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе, Мәгариф министрлыгы, Төзелеш Министрлыгы, прокуратура һәм җирле үзидарә органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә каралды.

Мөрәҗәгатьләрне һәрьяклап, объектив карау максатларында 2024 елда Вәкаләтле вәкил компетентлы органнар һәм ведомстволарны чакырып киңәшмәләр үткәрде.

Вәкаләтле вәкилгә, Казан шәһәрендә яшәүче гражданка Ф. ның улы мәнфәгатьләрендә, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык комитеты»ның торак урынны социаль наем шартнамәсенә өстәмә килешү төзүдән баш тартуы белән килешмәве турында мөрәҗәгать килгән. Мөрәҗәгать текстыннан күренгәнчә, мөрәҗәгать итүченең улына идарәче оешма тарафыннан социаль наем шартнамәсенә өстәмә килешү төзү кирәклеге турында хәбәр җибәрелгән, әмма Казан шәһәренең җирле үзидарә органы, торак урын башка физик зат милкендә булу сәбәпле, әлеге килешүне төзүдән баш тарткан.

Мөрәҗәгатьне карау йомгаклары буенча без Казан шәһәренең җирле үзидарә органы карар кабул иткәндә фатирларның нумерациясен үзгәртү исәпкә алынмавын, шуңа бәйле рәвештә җирле үзидарә органының торакның башка физик зат милкендә булуы турындагы дәлилләре фактлагы хәлләргә туры килмәвен ачыкладык.

Әлеге мөрәҗәгатьне хәл итү максатларында, Вәкаләтле вәкил Казан шәһәренең җирле үзидарә органы һәм прокуратура органы вәкилләрен чакырып киңәшмә уздырды, аның нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүченең мәсьәләсе уңай хәл ителде.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 190 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## Индивидуаль торак төзелеше өлкәсендә гражданнарның хокукларын үтәү

Соңгы елларда Татарстан Республикасында индивидуаль торак төзелеше популярлаша бара. Төзелеш министрлыгы мәгълүматы буенча, 2024 елда 2.350 мең кв. метр индивидуаль торак файдалануга тапшырылган. Әлеге типтагы торакның җәлеп итүчәнлеге төзелешнең кыска сроклары һәм азрак бәясе, шулай ук кешеләрнең уңайлырак һәм сәламәт яшәү рәвешенә омтылуы белән аңлатыла.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил адресына индивидуаль торак йортлар төзү өлкәсендә мошенниклык очраклары турында мөрәҗәгатьләр керде, аларны карау йомгаклары буенча Вәкаләтле вәкил әлеге гражданнарның хокукларын яклау компетенциясе кысаларында чаралар күрде.

Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәрендә яшәүче гражданка К., шәхси эшмәкәрнең шәхси торак йорт төзү турында подряд шартнамәсендә каралган йөкләмәләрне объектны сатып алу өчен «Саклык банкы» ГАЖ мөрәҗәгать итүчесенә бирелгән кредит акчалары исәбеннән үтәмәве турында мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгать итүче шулай ук хәбәр иткәнчә, элегрәк ул полиция органына җинаять билгеләре буенча җинаять эше кузгату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән. Әмма мөрәҗәгать итүченең дәлилләре буенча кирәкле тикшерү чаралары, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгате полициянең башка бүлегенә юнәлтелүгә бәйле рәвештә, үткәрелмәгән.

Вәкаләтле вәкил кичекмәстән Татарстан Республикасы Прокурорына әлеге мөрәҗәгатьне карауны, мөрәҗәгать итүченең дәлилләре буенча тикшерү уздыруны һәм прокурор чараларын күрүне сорап мөрәҗәгать итте. Тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать авторының дәлилләре расланды, полиция бүлеге вазыйфаи затына карата прокуратура органы тарафыннан кимчелекләрне бетерү турында таләп җибәрелде.

Безнең адреска мондый мөрәҗәгатьләрнең күп тапкыр килүен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил 2024 елның октябрендә шулай ук «Сбербанк» ПАЖ идарәсе рәисе адресына «Сбербанк» ПАЖ реестрына кертелгән төзелеш компанияләрен тикшерү оештыруны сорап хат юллады. «Саклык банкы» вәкиле мөрәҗәгатеннән соң Идел-Нокрәт территориаль территориясендә подряд оешмаларына чираттан тыш мониторинг үткәрелде, аның нәтиҗәләре буенча намуссыз катнашучылар банк партнерлары исемлегеннән чыгарылды.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2024 елда 138 гражданның гаризасы буенча дүрт җинаять эше кузгатылган, әлеге җинаятьләрдән зыян 368 млн.сумнан артык күләмдә бәяләнә.

Индивидуаль торак йортлар төзегәндә гражданнарның хокукларын яклау һәм әлеге процессның «үтә күренмәлелеген» арттыру өчен, 2025 елның 1 мартыннан индивидуаль торак йортлар төзегәндә эскроу-счетлардан файдаланып исәп-хисап механизмы эшли башлаячак, ул күчемсез милек объекты төзелеше тәмамланганчы гражданнарның акчаларын махсус счетта саклауны күздә тота.

2024 елның сентябрендә Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин Россия Федерациясе Хөкүмәтенә, Россия Банкы белән берлектә торак йортлар төзүче юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән исәп-хисапның яңа механизмыннан файдалану мөмкинлеге турында халыкка киң мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә йөкләмә бирде.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 191 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип таныганда гражданнарның хокукларын үтәү**

Татарстан Республикасында торак тармагын тотрыклы үстерүгә кучү проблемасын комплекслы хәл итүгә юнәлдерелгән дәүләт торак сәясәтенең бурычларыннан берсе булып, авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү тора.

Төзелеш министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2017 елның 1 гыйнварыннан республикада 73 мең кв.метр мәйданлы 162 күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, дип табылган, аларда 5,5 мең кеше яши. Узган елда 7 күпфатирлы йорт авария хәлендә дип табылган. Әлеге йортлар нигездә Казан шәһәрендә (111 йорт), Яшел Үзән (19 йорт) һәм Чистай (10 йорт) муниципаль районнарында урнашкан.

2024 елда тотылмаган акчалар чигендә 2024 елга гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасы төзелде, аның нигезендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң шундый дип танылган күпфатирлы авария хәлендәге йортлардан кешеләр күчерелергә тиеш.

Әлеге программа кысаларында агымдагы елда Казан шәһәре территориясендәге 4 авария хәлендәге йортта урнашкан гомуми мәйданы 574,7 кв.метр булган 17 бинадан 60 кеше күчерелгән.

Вәкаләтле вәкил адресына торак урыннарны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм җимерелергә һәм реконструкцияләнергә тиешле дип тану мәсьәләсе буенча гражданнардан мөрәҗәгатьләр килүгә һәм гражданнарның хокукларын бозуларны ачыклауга бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан җирле үзидарә органнары тарафыннан торак урынны яшәү өчен яраксыз дип, авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә дип таныганда, шулай ук гражданнарның маневр фондыннан торак бирүгә хокукларын тормышка ашыруга закон таләпләрен үтәү эшен оештыру мониторингы үткәрелде.

Мониторинг барышында Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре Татарстан Республикасының биш муниципаль районына барды: Апас (08.08.2024), Буа (08.08.2024), Алабуга (20.08.2024) Чистай (18.09.2024), Әлмәт (16.10.2024).

Әлеге районнар очраклы гына сайланмаган, сайлап алу критерие булып, яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыннары яки авария хәлендә дип танылган һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлар булу, шулай ук муниципаль берәмлектә маневр фонды булдыру.

Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге белән танышу барышында гражданнарга торак урыннарны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортларны авария хәлендә дип тану буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү материаллары сайлап өйрәнелде, шулай ук маневр фондына кертелгән торак урыннарны сайлап карап чыктылар.

Мониторинг йомгаклары буенча җирле үзидарә органнарының бу өлкәдәге эшендә уңай тенденцияне билгеләп үтәргә кирәк. Вәкаләтле вәкилнең 2022, 2023 елларга эшчәнлеге турында докладларда бәян ителгән торак урыннарны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортларны авария хәлендә дип тану очрагында хокук бозуларны бетерү буенча тәкъдимнәр, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 192 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителде һәм муниципаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертелде.

Әмма эшчәнлекнең бу юнәлешендәге кайбер мәсьәләләр хәл ителмәгән булып кала. Аерым алганда, ведомствоара комиссия бәяләмәсе нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында муниципаль норматив акт кабул ителмәү, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортны гражданнарны күчерүнең конкрет һәм дөрес срокларын билгеләмичә авария хәлендә һәм җимерелергә тиеш, дип тану турында карарлар чыгару очраклары ачыкланды.

Әйтик, Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органы эшенә мониторинг ясаганда, без, Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану турындагы карарлары белән гражданнарны күчерү сроклары, авария хәлендә дип танылган күпфатирлы йортлардан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын гамәлгә ашыру срокларыннан чыгып билгеләнүен билгеләп үттек.

Шул ук вакытта әлеге күпфатирлы йортлар 2019 - 2025 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасына кертелмәгән.

Әлеге хәлләр гражданнарның торак хокукларын гамәлгә ашыру срокларының дөреслеге принцибына җавап бирмәү сәбәпле, Вәкаләтле вәкил Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына, Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану турындагы карарларын торак законнары таләпләренә туры китерергә кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрде.

Вәкаләтле вәкилнең тәкъдимнәре үтәлде, хәзерге вакытта муниципаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертелде.

**Маневр торак фондыннан торак урыны биргәндә гражданнарның хокукларын үтәү**

2024 елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан маневр фондыннан гражданнарга торак урыны бирү хокукын гамәлгә ашыруга зур игътибар бирелде.

Торакны югалткан очракта, ул яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта, гражданнарның вакытлыча торак бирү рәвешендәге дәүләт гарантиясеннән файдалана алуы бик мөһим.

Маневр торак фондын төзү турыдан-туры законда каралган һәм нинди дә булса шартларга, шул исәптән агымдагы мохтаҗлыкка, зарурлыкка, максатка ярашлылыкка, социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗлар сыйфатында исәптә торучы затлар санына бәйле түгел.

Шул ук вакытта, җирле үзидарә органнары биргән мәгълүматны анализлау йомгаклары буенча, 2024 елның декабрь башына тугыз муниципаль районда маневр торак фонды юк (Алексеевск, Әтнә, Баулы, Кайбыч, Мамадыш, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Теләче муниципаль районнары).

Муниципаль берәмлек территориясендә маневр торак фондының җитәрлек күләмдә булмавы, Россия Федерациясе Торак кодексының 95 нче маддәсендә санап үтелгән аерым хәлләр аркасында алар тораксыз калганда, гражданнарның торак хокукларын бозу куркынычы тудыра.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 193 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Әлеге хәлләр маневр торак фонды төзелмәгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан ныклы игътибар таләп итә.

Маневр торак фондын булдыру һәм карап тоту мәсьәләләре прокуратура органнарының да аерым контролендә тора. Әйтик, 2024 елда гына да прокуратура органнары тарафыннан, судка җирле үзидарә органнарына гражданнарның маневр торак фондыннан вакытлыча торак бирүгә хокукларын гамәлгә ашырганда торак законнарын бозуларны бетерү турында 11 дәгъва гаризасы җибәрелгән.

Кайбер муниципаль районнарда маневрлы торак фонды төзелсә дә, санитар-техник таләпләргә туры килми, бу әлеге торак биналардан тиешенчә файдалана алмауга китерә.

Махсуслаштырылган торак фондының кайбер торак биналарында косметик ремонт үткәрү, атап әйткәндә, чүп-чарны чыгару, идән өслеген өлешчә алыштыру, стеналарны буяу таләп ителә. Ә кайбер торак биналар зуррак һәм чыгымлырак ремонт эшләрен таләп итә, атап әйткәндә: инженер системаларын, җылыту радиаторларын, сантехниканы алыштыру. Маневр фондының торак урыннарының бер өлеше тулай торакларда урнашкан, Чистай шәһәрендә яшәүче гражданка У.ның санитария-техник таләпләргә җавап бирә торган маневр фондыннан торак урын бирүдә ярдәм күрсәтү турындагы мөрәҗәгате әлеге мәсьәләнең актуальлеген раслый торган мисалларның берсе булып тора.

Мөрәҗәгать текстыннан күренгәнчә, мөрәҗәгать авторының торак йорты елга яры буенда куркыныч зонада урнашу сәбәпле, ул яшәү өчен яраксыз дип табылган. Мөрәҗәгать итүчегә Чистай шәһәре җирле үзидарә органы тарафыннан вакытлыча яшәү өчен маневр фондының торак биналары тәкъдим ителде. Әмма мөрәҗәгать авторы махсус торак фондының вакытлы торагыннан баш тартырга мәҗбүр була, чөнки ул санитар-техник таләпләргә җавап бирми.

Әлеге мөрәҗәгатьне тикшерү барышында Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим ителгән маневр торак фондының торак урыннарын карады. Карау йомгаклары буенча мөрәҗәгать итүченең күрсәтелгән торак урыннарда косметик ремонт үткәрү кирәклеге турындагы дәлилләре расланды. Хокук бозулар ачыклануга бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил Чистай шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе адресына маневр фондының торак урыннарын тиешле хәлгә китерү буенча тулы чаралар күрү, шулай ук мөрәҗәгать итүчене маневр фондының санитария-техник таләпләргә җавап бирә торган торак урыны белән тәэмин итү буенча чаралар күрү кирәклеге турында тәкъдимнәр белән хат җибәрде.

Әлеге хатны карау йомгаклары буенча Чистай шәһәре җирле үзидарә органы мөрәҗәгать итүчегә алга таба бирү өчен маневр фондының торак урынында косметик ремонт үткәрү, шулай ук маневр фондының башка торак биналары составына кертү мөмкинлеген карау турында карар кабул итте.

Маневр фондының торак урыннарын тиешле санитар-техник хәлгә китерү зарурлыгы Вәкаләтле вәкилнең Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрелгән хатында да билгеләп үтелде, ул Әлмәт шәһәрендә яшәүче гражданка Х.ның маневр торак фондына торак урын бирү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатен урынга чыгып карау йомгаклары буенча җибәрелгән иде.

Ачыкланган кисәтүләрне бергәләп тикшерү һәм хәл итүне эзләү кирәклеген исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты вәкилләре



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 194 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

катнашында «Торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип таныганда гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру» темасына Вәкаләтле вәкил карамагындагы эксперт советы утырышын оештырды.

Ачыкланган проблемалы мәсьәләләрне исәпкә алып:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына:

- маневр торак фонды булмаган муниципаль районнарның (Алексеевск, Әтнә, Баулы, Кайбыч, Мамадыш, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Теләче муниципаль районнары) җирле үзидарә органнарына муниципаль берәмлектә маневр торак фонды булдыру буенча чаралар күрергә (маневр фонд төзегәндә маневр торак фондында яшәүчеләрнең санын, вакытлыча торакка ихтыяҗын исәпкә алырга; эре торак пунктларда маневр фонды торак урыннарына транспорт белән барып җитү мөмкинлеген исәпкә алырга);

- маневр торак фондының торак урыннарын тикшерү, шул исәптән санитария-техник таләпләргә җавап бирми торган торак урыннарын фондка кертмәү максатыннан;

- маневр фондының торак урыннарын санитария, янгынга каршы һәм техник таләпләргә туры китерү чараларын күрергә;

Республикада «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләрне патриотик тәрбияләү» ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла, аның кысаларында патриотик тәрбия системасын модернизацияләү һәм гражданлык үзаңын формалаштыру, яшәүче халыкларның рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә гомумроссия гражданлык үзенчәлеген ныгыту чаралары гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы территориясендә гражданлык җаваплылыгы, Россия тарихы өчен горурлык хисе, гражданнарны хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерләү чаралары, патриотик тәрбия



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 224 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

өлкәсендә мәгълүмати, фәнни-теоретик һәм методик тәэмин итү чаралары тормышка ашырыла.

Мәгариф оешмаларының патриотик тәрбия буенча эшенә анализ ясап, без мәктәпләрдә һәм колледжларда укучыларны патриотик тәрбияләү буенча планлы эш оештырылуын билгеләп үттек: гимн башкару һәм флаг күтәрү тантанасы үткәрелә, шулай ук тарих буенча бердәм дәреслек кертелгән, «Мөһим әйберләр турында сөйләшү» дәрестән тыш чаралары үткәрелә.

Әлеге эшне камилләштерү максатларында Вәкаләтле вәкил Батырлык дәресләрен һәм Ватанны саклаучылар һәм геройлар истәлеген мәңгеләштерүгә юнәлдерелгән патриотик акцияләрне оештыру эшен дәвам итәргә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылар белән даими нигездә очрашулар оештырырга тәкъдим итә. Батырлык дәресләре горурлык һәм хөрмәт хисе белән тулыланырга, балалар махсус хәрби операциядә катнашкан якыннары – әтисе, абыйсы, күршесе, танышы турындагы тарихлары белән уртаклашырга тиеш. Бу тарихлар безгә гади кешеләрнең чын геройларга әверелүен һәм аларның тынычлыкны саклауда роле никадәр мөһим булуын күрсәтергә тиеш. Шулай ук һәр гомуми белем бирү оешмасында «Геройлар истәлеге» почмакларын булдыруны тормышка ашыру мөһим. Бу Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин тарафыннан Ватанны саклаучылар елы, дип игълан ителгән 2025 елда аеруча мөһим.

Низаглы хәлләрне чишү мәсьәләләре

Вәкаләтле вәкилнең даими игътибарында мәгариф оешмалары тарафыннан имин, психологик яктан уңайлы белем бирү мохите булдыру мәсьәләләре булды.

Соңгы вакытта мәктәпләрдә буллинг темасына мөрәҗәгатьләр саны артты. Мөрәҗәгатьләрдә укучыларның бер-берсенә карата рәхимсез формада (кимсетү формасында озак вакытлы сүз белән мыскыллау, укучының гомеренә һәм сәламәтлегенә янаулар) агрессия ешрак чагыла һәм мәктәпләр администрациясе низаглы хәлләрне җайга салу буенча нәтиҗәле чаралар күрми, дип күрсәтелә.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен 7 нче Казан мәктәп-интернаты», Казан шәһәре Киров районының «153 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе», Казан шәһәре Идел буе районының «Катнаш төрдәге 138 нче балалар бакчасы»нда килеп туган низагларны карауда актив катнаштылар. Шулай ук «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Югары Чаллы мәктәп-интернаты», «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 86 нчы номерлы «Өмет» «Яр Чаллы мәктәбе», Казан шәһәре Киров районының «182 нче политехник лицее», Казан шәһәренең «Волна» спорт мәктәбе, Казан шәһәре Совет районының «Катнаш төрдәге 213 нче балалар бакчасы» һәм башкалар. Вәкаләтле вәкил күрсәтелгән мәгариф оешмаларында конфликтларда катнашучылар белән эшлекле очрашулар уздырды, чаралар күрү өчен вәкаләтле органнарга, шул исәптән күзәтчелек органнарына мөрәҗәгатьләр җибәрде. Барлык мөрәҗәгатьләр Вәкаләтле вәкил контролендә булды.

Хосусый мәгариф оешмаларында гражданнар хокукларын яклау мәсьәләләре

Хокук яклау практикасын анализлау күрсәткәнчә, хосусый белем бирү оешмалары эшчәнлеге белән бәйле мәсьәләләр елдан-ел актуальлеген югалтмый.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 225 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итеп, гражданнар белем бирү хезмәтләрен күрсәтү шартнамәсе шартларының бозылуы, белем бирү процессының бозылуы, мәгариф оешмасы бинасының торышы канәгатьләнерлек булмавы турында һ. б. хәбәр итәләр.

Коммерция оешмаларына карата мөрәҗәгатьләрне карау вәкаләтләре булмау сәбәпле, әлеге мөрәҗәгатьләр Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең территориаль органнары, Департамент адресына җибәрелде.

Вәкаләтле вәкил адресына граждан К.ның «ЭдЭкс» ҖЧҖ (Urban University) эшчәнлегенә шикаять белән мөрәҗәгате кергән. Анда мөрәҗәгать итүче белем бирү процессын оештыру өлешендә шартнамә шартларын бозу һәм түләнгән акчаларны кире кайтарудан баш тарту турында күрсәткән.

Вәкаләтле вәкил Департамент җитәкчесе һәм Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (алга таба – Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе) җитәкчесе адресына мөрәҗәгать итеп, мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен тикшерүне оештыруны сорады.

Хатыбызны карау нәтиҗәләре буенча акча мөрәҗәгать бирүчегә тулы күләмдә кайтарылды.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2024 елда Департаментка «ЭдЭкс» ҖЧҖ гамәлләренә карата 60 шундый мөрәҗәгать кергән.

Кергән мөрәҗәгатьләрне карау барышында Департамент тарафыннан «ЭдЭкс» ҖЧҖнең белем бирү эшчәнлеген алып баруны регламентлаучы документлары берничә мәртәбә анализланды.

2024 елның июлендә Департамент белгечләре закон бозуларга юл куймас өчен әлеге җәмгыятькә барып профилактик эш уздырды.

## Балаларны мәктәп автобусы белән йөртүне оештыру мәсьәләләре

Вәкаләтле вәкил эшчәнлегендәге тагын бер мөһим юнәлеш - белем бирү процессында катнашучыларның белем бирү оешмаларына илтеп җиткерүне оештыру өлешендә хокукларын яклау һәм йөртү куркынычсызлыгы.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил адресына балаларны мәктәп транспортында йөртүне оештыру буенча мөрәҗәгатьләр килде.

Вәкаләтле вәкилгә «Царицын калкулыгы» торак массивында яшәүче балаларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) Казан шәһәре Совет районының «Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназия»гә әлеге бистәдән балаларны йөртү өчен мәктәп автобусы булмау турында мөрәҗәгать килде. Вәкаләтле вәкил инициативасы белән Казан шәһәренең Совет районы прокуратурасы тарафыннан, белем бирү оешмасының һәркем файдалана алуын тәэмин итү буенча тикшерү оештырылды, аның нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең дәлилләре расланды. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү максатыннан прокуратура органы тарафыннан прокурор чаралары күрелде. Докладны язу вакытына прокурор чарасы акты карауда иде.

Башка мисал. Татарстан Республикасы Прокуроры белән бергәләп гражданнарны кабул итү кысаларында, Вәкаләтле вәкил адресына «Фәйзрахман Сәлах улы Юнысов исемендәге Кама Тамагы татар урта гомуми белем бирү мәктәбе»нә укучыларны алып килүне оештырганда закон таләпләрен бозу



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 226 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

турында мөрәҗәгать килде. Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгате буенча Кама Тамагы районы прокуратурасы тарафыннан тикшерү оештырылды. Тикшерү барышында укучыларны мәгариф оешмасыннан Олы Мәрәтхуҗа авылына алып бару маршрутының санитария-эпидемиология законнарында билгеләнгән нормативлардан артып китүе ачыкланды. Район прокуратурасы тарафыннан Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына федераль закон таләпләрен бозуларны бетерү турында күрсәтмә кертелде. Прокурор чарасы акты канәгатьләндерелде, гаепле зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды. Закон бозу бетерелде, мәктәп автобусы хәрәкәте маршруты паспортына үзгәрешләр кертелде, маршрут озынлыгы санитар-
эпидемиология таләпләренә туры китерелде.

Гражданнарның белем алуга хокукларын үтәү мәсьәләләре барлык кызыксынган яклардан даими мониторинг һәм актив гамәлләр таләп итә. Гражданнарның мәгарифкә хокукларын саклауны бары тик уртак һәм бердәм көчләр белән генә тәэмин итәргә мөмкин, бу, үз чиратында, җәмгыятьтә гомуми белем бирү мохитен һәм социаль климатны яхшыртуга китерәчәк.

### 4.6. Гаилә хокукларын һәм гаилә кыйммәтләрен саклау

Гаиләне яклау, традицион гаилә кыйммәтләрен саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен популярлаштыру максатларында, Россия Федерациясе Президенты Указы белән 2024 ел Россия Федерациясендә Гаилә елы дип игълан ителде.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасында гаилә традицион кыйммәтләренең мөһимлеген ассызыклады: «Гаилә – безнең күпмилләтле дәүләтебезнең нигезе, һәр кеше өчен ышанычлы тыл һәм таяныч. Ул традицион кыйммәтләрне ныгыта, буыннар дәвамчанлыгын саклый».

Игълан ителгән Гаилә елы кысаларында 2024 елда республикада барлык муниципаль берәмлекләрдә төрле форматтагы 1400дән артык чара уздырылган. Вәкаләтле вәкил күрсәтелгән чараларда актив катнашты, шулай ук аларны оештырды.

2024 елның 14 маенда, Халыкара гаилә көне кысаларында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге, «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы, «Бөтенроссия дәүләт юстиция университеты» югары һөнәри белем бирү учреждениесенең Саранск шәһәрендәге Урта Идел институты (филиалы), югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Казан институты (филиалы) белән берлектә, Вәкаләтле вәкил тарафыннан «Гаилә һәм патриотизм: махсус хәрби операция чорында кеше хокукларын тәэмин итү ресурслары» Идел буе демографик форумы оештырылды. Форум фәнни җәмәгатьчелек, дәүләт һәм иҗтимагый структуралар вәкилләрен, ветераннарны һәм катнашучыларны берләштерде.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил Аппараты шулай ук гаиләләрне яклау мәсьәләләре буенча алты «кайнар элемтә» үткәрде, алар барышында 246 шалтырату кергән.

Гаилә елында үсеш үзенчәлекләре булган балалар тәрбияләүче гаиләләргә ярдәм итүгә аерым игътибар бирелде. 2024 елның 27 апрелендә социаль инициативаларны үстерү ассоциациясе (АРСИ), Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә «Аерым гаиләләргә – аерым кайгырту» темасына «түгәрәк өстәл»



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 227 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

оештырды. Чара йомгаклары буенча муниципаль берәмлекләр һәм шәһәр округлары җитәкчеләренә ата-аналар билгеләгән актуаль мәсьәләләре буенча киңәш-тәкъдимнәр әзерләдек.

Вәкаләтле вәкил инвалид балаларның ата-аналарына социаль инициативаларны үстерү ассоциациясе (АРСИ) белән берлектә үткәрелгән «Инвалид балаларның ата-аналары өчен «Хокукый белемнәр мәктәбе» проекты аша хокукый ярдәм күрсәтте. «Яндекс.Телекүпер» аша 2024 елда җиде дәрес үткәрелде.

Вәкаләтле вәкил күп тапкыр массакүләм мәгълүмат чараларында гаиләне һәм гаилә кыйммәтләрен саклау темасын яктыртты.

2024 елның 16 февралендә Татарстан Республикасы төбәк белән идарә итү үзәге базасында, Вәкаләтле вәкил Татарстанда гаилә очраша торган мәсьәләләрне һәм проблемаларны хәл итүгә багышланган туры эфирда катнашты. Эфир язмасы 40 меңнән артык карау җыйган.

Россия Федерациясе Президентын сайлауларда тавыш бирү көнендә (2024 елның 17 марты) Вәкаләтле вәкил «Бөтен гаилә белән сайлауларга» гаилә телемарафонында катнашты, анда ул үз тәҗрибәсеннән чыгып, гаилә кыйммәтләренең мөһимлеге турында сөйләде.

Ел дәвамында безнең тарафтан «Россия Федерациясе субъектларында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 18.03.2020 ел № 48-ФЗ Федераль законы һәм «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 03.03.2000 ел 95 нче Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән юнәлешләр һәм инструментлар кысаларында Гаилә, ана, ата һәм балалар хокукларын үтәүне һәм яклауны мониторинглау буенча төрле эшләр башкарылды.

## Гаиләләргә социаль яклау чаралары күрсәтү

Мөрәҗәгатьләрне анализлау балалы гаиләләр өчен актуаль мәсьәләләрнең берсе - социаль ярдәм күрсәтү булуын күрсәтә.

Татарстан Республикасында гаиләләргә ярдәм системалы нигездә төзелгән һәм, беренче чиратта, дәүләтнең махсус ярдәменә мохтаҗ гаиләләргә – аз керемле, күпбалалы, инвалид балалы гаиләләргә юнәлдерелгән.

2024 елда балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүгә 32 млрд.сум юнәлдерелгән, шул исәптән ТР бюджетыннан – 16,8 млрд. сум. (Республика бюджетыннан 1,3 млрд. сум күп балалы гаиләләргә ярдәм итүгә юнәлтелә), Россия Федерациясе Пенсия һәм Социаль иминият Фондының Татарстан Республикасы буенча акчалары – 15,2 млрд.сум.

Балалары булган аз керемле гаиләләр, федераль ярдәм чараларыннан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән дә ярдәм алалар:

- Балалар бакчасы өчен түләүнең 100 процент компенсациясен (2024 елда – 3,9 мең бала);
- аз керемле гаиләләрдәге 3 яшькә кадәрге балаларга дарулар сатып алу өчен елга 10 мең сум күләмендә түләү (2024 елда алучылар - 6,2 мең бала);
- яңа туган балалар өчен кирәк-яраклар комплекты (2024 елда - 2,2 мең бала).

Авыл җирендә яшәүче хатын – кызларга бер тапкыр бирелә торган демографик чара булып тора: беренче бала туганда, 25 яшькә кадәрге хатын – кызларга - 50 мең сум, өченче һәм аннан соңгы һәр бала туганда 29 яшькә кадәрге хатын-кызларга - 100



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 228 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

мең сум. 2018 елдан – 14,1 мең хатын – кыз, шул исәптән 2024 елда - 1,5 мең хатын-кыз.

Россия Федерациясе Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 23.01.2024 ел № 63 Указы нигезендә күп балалы гаиләләргә өстенлекле тәртиптә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү хокукы бирелде. 2024 елның 1 декабренә республикада 5 644 социаль контракт төзелгән, алар 11 648 кешене колачлаган, шуларның 2 190ы балалы гаиләләр белән - социаль контракт, 518 е - күп балалы гаиләләр белән. (2 647 кеше, ягъни социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме алган гражданнарның гомуми санының 23% ы).

2024 елда (06.12.2024 көненә) Россия Федерациясе Пенсия һәм Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге тарафыннан гаилә мохтаҗлыгын комплекслы бәяләү нәтиҗәләре буенча, керемнәрне, мөлкәти тәэмин ителешне һәм хезмәт потенциалын бәяләүне дә кертеп, бала тууга һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие түләү һәм беренче бала тууга бәйле рәвештә айлык түләү турында 90,0 меңнән артык карар кабул ителде.

Шул ук вакытта, хисап чоры дәвамында Вәкаләтле вәкил адресына бала туу һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә пособие билгеләүдән баш тартуга карата шикаятьләр керде. Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре мондый һәр мөрәҗәгатьне законлылык һәм нигезлелек предметына тикшерде.

Тиешле тематика буенча мөрәҗәгатьләрне анализлау нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләргә пособие билгеләүдән баш тартуның төп сәбәбе - гаиләнең җан башына уртача кереме күләменең җан башына яшәү минимумы күләменнән артып китүе, шулай ук бала туу һәм тәрбияләү белән бәйле айлык пособие түләү һәм билгеләү кагыйдәләренең 31 пунктындагы «Л» бүлегендә каралган аерым очракларда, аерым алганда, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 16.12.2022 №2330 карары белән расланган балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» (алга таба – 2330 номерлы кагыйдә) федераль законда билгеләнмәгән өлештә мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) хезмәткә сәләтле гаилә әгъзаларының керемнәре булмавы расланмау.

Мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге гражданнарга балаларга пособие билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр турында җитәрлек мәгълүмат бирелмәү белән бәйле. Шуңа бәйле рәвештә Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы буенча Социаль иминият фонды белән хезмәттәшлек иткәндә гражданнарга 2330 нчы кагыйдә нигезләмәләрен аңлатуга юнәлдерелгән язма хокукый консультация рәвешендә ярдәм күрсәтте.

Аерым очракларда Вәкаләтле вәкил бердәм пособие билгеләүдән баш тарту турындагы карар белән килешмәвен белдерде.

Мәсәлән, гражданнарны шәхсән кабул итү кысаларында Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәрендә яшәүче гражданка М.мөрәҗәгать итте, аның һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының милкендә «Торак» билгеләнешендәге ике һәм аннан күбрәк урын булуга бәйле рәвештә, бер кешегә исәплләгәндә суммар мәйдан 24 кв.метрдан артып китү һәм гаилә әгъзалары санына карап, бердәм пособие билгеләүдән баш тарту мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте.

Тәкъдим ителгән документларны өйрәнгәннән соң, вәкаләтле орган бердәм пособие билгеләүдән баш тарту турында карар кабул иткәндә, торак урыннарның берсенең Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 29 ноябрьдәге боерыгы белән расланган авыр формадагы хроник авырудан интегүче инвалид балага



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 229 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

бирелүен исәпкә алмаган. Ул 2012 ел № 987н «Гражданнарның бер фатирда бергә яшәве мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлеген раслау турында» Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы буенча җирле үзидарә органының күрсәтмәсе нигезендә социаль наем шартнамәсе буенча чираттан тыш тәртиптә бирелә.

Әлеге гаиләнең хокукларын яклау максатларында, вәкаләтле орган позициясе белән килешмичә, без югарыда бәян ителгән фактны исәпкә алу кирәклеге турында мөрәҗәгать юлладык. Безнең катнашуыбыздан соң гариза бирүчегә балага бердәм пособие билгеләнде.

Районнарга чыгып, халык белән актив хезмәттәшлек итү һәм проблемалы мәсьәләләрне билгеләү максатларында Вәкаләтле вәкил гаиләләр белән очраша, аз керемле, күп балалы, тәрбиягә бала алган гаиләләр мәсьәләләренә аерым игътибар бирә.

Мәсәлән, Аксубай районында гражданнарны шәхсән кабул итү барышында тәрбиягә бала алган балаларны тәрбияләүче гражданка А.безнең адреска опекуннарга һәм попечительләргә Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141.1 статьясында каралган түләүнең түбән күләмдә булуы турында мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгатьне карау кысаларында без үз вазыйфаларын башкаручы опекуннарга яки попечительләргә тиешле түләү күләменең 2013 елдан бирле индексацияләнмәвенә һәм артмавына игътибар иттек.

Опекуннарга һәм попечительләргә түләүне арттыру һәм аны ел саен инфляция дәрәҗәсен исәпкә алып, индексацияләү мәсьәләсен башлап җибәрү өчен, Вәкаләтле вәкил Мәгариф министры адресына хат юллады. Хатыбызга җавап итеп, Мәгариф министрлыгы мәсьәләне хәл итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә мөрәҗәгать итү турында хәбәр итте. Докладны язу вакытында әлеге хат карауда иде. Вәкаләтле вәкил әлеге мәсьәләне уңай хәл итүгә өметләнә.

Чирмешән районында район башлыгы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Тарханова белән бергәләп гражданнарны кабул итү барышында безгә ике баланың опекуны булган гражданка С. мөрәҗәгать итте. Олы бала «Лениногорск нефть техникумы»нда түләүле нигездә белем алган. Авыр тормыш хәленә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүченең баланың укуына түләү мөмкинлеге булмаган. Мөрәҗәгать итүченең тормыш хәлен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил, шулай ук Чирмешән муниципаль районы җитәкчелеге «Лениногорск нефть техникумы» директоры адресына балигъ булмаган баланың опекуны мөрәҗәгате буенча, үсмерне бюджет төркеменә күчерү мөмкинлеген карау үтенече белән хат юлладык. Мөрәҗәгатебезне карау нәтиҗәләре буенча мәгариф оешмасы җитәкчелеге тарафыннан уңай карар кабул ителде.

**Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балаларның һәм ятим балаларның хокукларын яклау**

Узган елда Вәкаләтле вәкил шулай ук ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын үтәү мәсьәләләренә аерым игътибар бирде.

Республикада ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны кимү буенча уңай тенденция күзәтелә. 2018 елда республикада 11 136 ятим бала исәпләнсә, 2024 елда – 8644 бала.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 230 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстанда ятим балалар өчен 13 учреждение эшли, шул исәптән сигез балалар йорты, инвалид балалар өчен ике интернат-мәктәп, психик тайпылышлары булган гражданнар өчен ике интернат-йорт һәм Сәламәтлек саклау министрлыгының балалар йорты, аларда тәрбияләнүчеләрнең гомуми саны 409 бала тәшкил итә.

2024 елга эш планы нигезендә без балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, Мәгариф министрлыгы, муниципаль берәмлекләрнең опека һәм попечительлек органы вәкилләре белән берлектә, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар учреждениеләре эшчәнлегенә, анда яшәүче һәм тәрбияләнүче ятим балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү мәсьәләсенә мониторинг уздырдык.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, мониторинг, беренче чиратта, әлеге учреждениеләрнең эшчәнлеге белән танышуга, шулай ук аларны алга таба өйрәнү өчен системалы мәсьәләләрне ачыклауга, фикер алышуга һәм аларны хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләүгә юнәлдерелгән иде.

Мониторинг ике этапта узды: беренче этапта без статистика мәгълүматларын сорадык һәм анализладык, икенче этапта турыдан-туры учреждениеләргә бардык. Мониторинг кысаларында без алты учреждениедә булдык: «Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Югары Утар балалар интернат-йорты», «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 11 нче Казан мәктәп-интернаты», «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен Минзәлә мәктәп-интернаты», «Лениногорск балалар йорты», «Әлмәт балалар йорты», Яшел Үзән районының «Норлат балалар йорты».

Мониторинг нәтиҗәләре Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советы утырышында Россия Федерациясе Дәүләт Думасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары, опека һәм попечительлек органнары, муниципаль мәгариф идарәсе органнары, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар учреждениеләре җитәкчеләре катнашында тикшерелде.

Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советы утырышында белем бирү процессын, һөнәри үзбилгеләнүне, һөнәри юнәлеш бирү эшен, ятим балаларны һәм тәрбиядән мәхрүм балаларны тәрбияләү һәм үсешен тәэмин итү эшләрен оештыру, ятимнәрнең мөлкәткә хокукларын саклау, интернаттан киткәннән соң булышу буенча тәкъдимнәр эшләнде.

*Мисал өчен:*

Мәгариф министрлыгына, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларына ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик ярдәм күрсәтүне оештыруда системалы нигездә ярдәм күрсәтергә һәм учреждениеләрдә психологик климатны бәяләү эшен елга кимендә 1 мәртәбә башкарырга тәкъдим ителде;

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә ведомство киңәшмәсе уздырырга һәм структур бүлекчәләргә ятим



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 231 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны матди карап торуга алиментны мәҗбүри түләтү эшен оештыру мәсьәләләренә зур игътибар бирергә һәм ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмалары белән тыгыз хезмәттәшлек оештырырга тәкъдим ителде;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләренә, муниципаль берәмлек территориясендә эшләүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларына, предприятиеләр белән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган балаларны һәм яшүсмерләрне һәрьяклап үстерүгә һәм социализацияләүгә ярдәм итә торган һөнәри юнәлеш бирү эше буенча хезмәттәшлек турында килешү төзүдә ярдәм күрсәтергә;

«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт учреждениесенә педагоглар, психологлар, сыйныф җитәкчеләре, мәктәп һәм балалар йортлары тәрбиячеләре өчен ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны тәрбияләүгә, укытуга һәм үстерүгә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча квалификация күтәрү буенча махсус программалар (яисә аерым модульләр) эшләргә;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә - елына кимендә бер тапкыр комиссиянең киңәйтелгән утырышында ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балаларның хокукларын яклау буенча ведомствоара эшне оештыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим ителде.

Әлеге тәкъдимнәрне үтәү Вәкаләтле вәкил контролендә кала.

**Социаль яктан куркыныч хәлдәге балигъ булмаган үсмерләрнең хокукларын яклау**

2024 елда Вәкаләтле вәкилгә «Глонасс+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы аша һәм башка чыганаклардан ата-аналарның балаларга карата үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәве турында мәгълүмат керде. Мондый мөрәҗәгатьләрне алганда, эшнең шартларын ачыклау өчен, Вәкаләтле вәкил муниципаль берәмлекләр (шәһәр округлары) җитәкчеләренә опека һәм попечительлек органына балигъ булмаган балаларның яшәү шартларын тикшерүне башкаруны йөкләү һәм кирәк булганда балалар хокукларын яклау максатларында чаралар күрү кирәклеге турында мөрәҗәгать итте.

Мисал өчен, ГЛОНАСС+112 системасы аша Чаллы шәһәрендә яшәүче гражданка Ш.дан күрше фатирда яшәүче хатын-кызның өч балигъ булмаган балага карата ата-ана бурычларын тиешенчә үтәмәве турында мәгълүмат алынды. Мөрәҗәгатьтә балаларның мәктәп яки мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрмәве, күп вакытларын урамда караусыз үткәрүләре, аларда имгәнүләр һәм җәрәхәтләр булуы турында хәбәр ителгән.

Алынган мәгълүматларга нигезләнеп, безнең йөкләмә буенча Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесе күрсәтелгән адрес буенча Чаллыга китте.

Кызыксынган органнар һәм ведомстволар вәкилләре белән аралашканда хәлләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүченең дәлилләре расланды.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 232 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Вәкаләтле вәкил тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгына әлеге гаилә белән эшне оештырырга, балаларны мәгариф оешмаларына урнаштыру буенча чаралар күрергә һәм бу хәлне ведомствоара социаль-тернәкләндерү консилиумы утырышында карарга кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрелде.

Башкарылган эш нәтиҗәләре буенча балалар мәгариф оешмаларына алынды, балаларның йөкле анасы хатын-кызлар консультациясенә исәпкә басты, «Чаллы наркология диспансеры» филиалында табиб-наркологта консультация үтте. Гаилә ведомствоара исәпкә алынды һәм социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм балигъ булмаганнар мониторингына алынды.

Хисап елында балигъ булмаган балалар һәм яшүсмерләрнең хокукларын яклау максатларында, Вәкаләтле вәкил һәм Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре белән берлектә, Чирмешән һәм Түбән Кама муниципаль районнарының социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләре белән эшне оештыру буенча профилактика субъектлары эшчәнлегенә анализ ясалды. Сәфәр барышында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең киңәйтелгән утырышын уздыру инициативасы белән чыктык, аның кысаларында социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм балигъ булмаганнар белән эшне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек мәсьәләләре каралды.

Гомумән алганда, 2024 елда республикада «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасы ярдәмендә профилактика системасы субъектлары тарафыннан 4020 сигнал картасы җибәрелде, 1674 гаиләдә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр карарлары белән социаль яктан куркыныч хәл булу факты расланды. Алар барысы да ведомствоара исәпкә куелган.

Вәкаләтле вәкил билгеләп үткәнчә, гаиләнең имин булмавын иртә ачыклау һәм социаль ятимлекне кисәтү - профилактика системасының барлык органнары эшенең өстенлекле юнәлеше булырга тиеш.

Россия Федерациясе Президенты тарафыннан игълан ителгән, ныклы гаилә булып торган традицион гаилә кыйммәтләрен хуплаган дәүләт гаилә сәясәте принципларын гамәлгә ашырып, ата-ана хокукларын чикләү яисә мәхрүм итү турында суд карар кабул иткән очракта, гаилә белән эшләүне төгәлләнгән дип санарга ярамый, ә закон чыгаручы тарафыннан гаилә мөнәсәбәтләрен торгызу мөмкинлекләреннән файдаланырга кирәк.

Хөкем ителгәннәргә "Хокукый ярдәм күрсәтү көне" кысаларында, Вәкаләтле вәкилнең шәхсән кабул итүе вакытында КП-17 учреждениесендә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче граждан Ш.мөрәҗәгать итте, ул ата-ана хокукларын торгызуда ярдәм итүне сорады.

Кабул итү кысаларында Вәкаләтле вәкил әлеге мәсьәләне хәл итү тәртибен аңлатты. Шулай ук Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә мөрәҗәгать итүчегә ата-ана хокукларын торгызуда ярдәм күрсәтү турында хат җибәрелде. Әлеге хатка җавап итеп, район администрациясе мөрәҗәгать итүчегә ата-ана хокукларын торгызу мәсьәләсен башлап җибәрү өчен бирелгән тәкъдимнәр турында хәбәр итте. Шул ук вакытта мөрәҗәгатьнең эчтәлегеннән без,



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 233 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

мөрәҗәгать итүчене эшкә урнаштыру буенча комплексы ярдәм күрсәтүне, медицина, психологик ярдәм күрсәтүне күрмәдек.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, җирле үзидарә органнарына ата-ана хокукларын торгызырга теләүче ата-аналар белән эшләүнең нәтиҗәлелеген арттыру буенча эшне көчәйтергә кирәк. Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән, яки ата-ана хокукларыннан чикләнгән, үзләренең ата-ана хокукларын кире кайтарырга ниятләгән ата-аналар белән эшләү буенча органнар һәм учреждениеләр эшчәнлеге яңадан торгызу процессын комплексы этаплап алып баруны күздә тотарга тиеш.

**Алиментлар алуга хокукны яклау**

Гаиләне, аналарны һәм балаларны дәүләт тарафыннан яклау өлкәсендә тагын бер актуаль тема - алимент түләтү булды. Әлеге тема буенча 30дан артык мөрәҗәгать килгән.

2024 елның 10 аенда Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсендә алимент түләтү турында 33738 башкарма эш башкарылган. Аларның саны узган ел белән чагыштырганда 3 меңгә (30 790) арткан. 8 656 башкарма эш кузгатылган, бу узган елгыдан 253 башкарма эшкә күбрәк (8 403).

16 521 башкарма эш тәмамланган һәм туктатылган, шуларның 1 503е фактта башкару белән тәмамланган. Алимент буенча 1,8 млрд сум бурыч түләтелгән (10 ай эчендә), бу 2023 елга караганда 793 млн.сумга күбрәк (926 млн. сум), чагыштырма саннарда 86% ка күбрәк.

Калган өлеше - 17 159 башкарма эш, узган ел белән чагыштырганда ул 2 549 эшкә (19 708) кыскартылган.

Хокук яклау практикасы шуны күрсәтә: балаларны карау өчен алимент түләү турындагы суд карарларын үтәмәүнең төп сәбәпләре: күп бурычлыларның беркайда да эшләмәве, асоциаль яшәү рәвеше алып баруы яки хезмәт килешүе төземичә эшләве белән бәйле, ә опись һәм кулга алынырга тиешле мөлкәтнең бурычлы кешедә булмавы белән бәйле.

Шул ук вакытта мөрәҗәгатьләрне карау кысаларында, кайбер очракларда Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең территориаль бүлекчәләре вазыйфаи затларының суд карарын мәҗбүри үтәү буенча тулы чаралар күрмәү фактлары ачыкланды.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил адресына баланың атасы тарафыннан алимент йөкләмәләрен үтәмәү, шулай ук суд приставлары тарафыннан суд карарын мәҗбүри үтәү буенча чаралар күрмәү турында гражданка Х.мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүченең хокуклары бозылуын күреп, Вәкаләтле вәкил Казан шәһәренең Идел буе районы прокурорына мөрәҗәгать итеп, мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен тикшерүне оештыруны сорады. Казан шәһәре Идел буе районы прокуратурасы вәкиле инициативасы белән тикшерү оештырылды, аның барышында суд карарын мәҗбүри үтәү буенча тулы чаралар күрелмәү факты ачыкланды. Моннан тыш, түләтелгән акчалар биш көнлек срокны бозып күчерелгән. Тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул ителде.

Башка мисал. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының хатын-кыз депутатлар «Мәрхәмәт-Милосердие» берләшмәсе белән берлектә оештырылган, Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көненә багышланган телефон “кайнар элемтәсе” кысаларында,



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 234 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

гражданка П.суд приставының түләтелгән акчаларны мөрәҗәгать итүче счетына күчерү буенча чаралар күрмәве турында мөрәҗәгать итте.

Барлык хәлләрне ачыклау өчен Вәкаләтле вәкил, суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе адресына хат җибәрде. Үткәрелгән тикшерү барышында башкару эшчәнлеге турындагы законнарны бозулар ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә Түбән Кама районы буенча 2 нче суд приставлары бүлекчәсе вазыйфаи затларына карата чаралар күрелде. Хокук бозулар бетерелде.

Күргәнебезчә, гаиләләр күп төрле сораулар һәм проблемалар белән очраша. Аларга ярдәм һәм социаль ярдәм күрсәтү - төп бурычларның берсе булып кала.

Быел да ана, ата һәм балалар хокукларын яклау буенча эш дәвам итәчәк.

## 4.7. Уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокук

Россия Федерациясе Конституциясе һәр гражданның экологик чиста мохиттә яшәү һәм аның торышы турында дөрес мәгълүматлар алу хокукын гарантияли. Бу конституцион хокук кешенең тормышына йогынты ясый торган төп хокукларына карый.

2024 елда Россия Президенты Владимир Владимирович Путин экологик иминлекне Россия үсешенең милли максатларының берсе, дип игълан итте һәм «Экология» илкүләм проектына алмашка килгән «Экологик иминлек» яңа илкүләм проектын эшләтеп җибәрүне игълан итте.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында республиканың илкүләм проектларда актив катнашуын һәм аларның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итү бурычын куйды.

2024 елда дәүләт тарафыннан уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокук гарантияләрен ныгытуга юнәлдерелгән масштаблы эш башкарылды. Хисап елында әйләнә-тирә мохитне саклауга чыгымнар 11 млрд.сумнан артып китте. Татарстан – әйләнә-тирә мохитне саклауга инвестицияләр күләме буенча Идел буе федераль округында лидер.

Иң эре федераль проект - «Иделне савыктыру» кысаларында 13 чистарту корылмасы төзелде һәм төзекләндерелде. Узган елда Казанның Идел елгасын пычратучы иң эре чистарту корылмаларын реконструкцияләү төгәлләнде. Шулай ук 2024 ел башына Озерное нефть ятмасының 24 чакрымга якын гамәлдә булмаган торба үткәргечләрен сүтү эшләре тәмамланган, бу Түбән Кама сусаклагычы суларына тискәре йогынты ясауның потенциаль куркынычын бетерергә мөмкинлек биргән, шулай ук башка чаралар гамәлгә ашырылган.

Әйләнә – тирә мохитне саклау максатында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы (алга таба - Экология министрлыгы) 2024 елда 1 370тән артык кисәтү игълан иткән, 475тән артык консультация һәм 125 профилактик визит үткәргән. Ачыкланган тәртип бозучылар буенча 2,2 млн. сумлык 115 административ штраф салынган, 85 кисәтү ясалган. Әйләнә-тирә мохит компонентларына зыян салу фактлары буенча Экология министрлыгы тарафыннан 320 дән артык дәгъва таләбе куелган, шуларның 120 се 106,2 млн.сумлык зыянны каплау турында.

Хисап елында Вәкаләтле вәкил төрле эшчәнлек юнәлешләре кысаларында гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 235 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

яклауда катнашты. Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил һәм Вәкил Аппараты хезмәткәрләре тематик утырышларда, фикер алышуларда катнаштылар, анда республика халкын борчыган экология һәм төзекләндерү мәсьәләләре күтәрелде, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләделәр.

Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы буларак һәм Татарстан Республикасында «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча проект офисы рәисе сыйфатында проект офисы мөрәҗәгатьләрен һәм хәбәрләрен карап, Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты әлеге категориядә бастырылган хәбәрләргә һәм мөрәҗәгатьләргә көндәлек мониторинг уздырды. Хәбәрләрне модерацияләү һәм анализлау йомгаклары буенча Вәкаләтле вәкил җаваплы башкаручыларга гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын яклау буенча 25 тән артык тәкъдим һәм киңәш җибәрде.

**Законсыз чүплекләр барлыкка килү мәсьәләләре**

2024 елда экология мәсьәләләре буенча Вәкаләтле вәкил адресына аз гына мөрәҗәгать кергән (30 мөрәҗәгать). «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында узган елда «Экология» юнәлеше буенча 1 371 мөрәҗәгать басылып чыкты, бу узган ел белән чагыштырганда 25% ка кимрәк. Гражданнардан иң күп мөрәҗәгатьләр «Чүплекләр» (676 мөрәҗәгать), «Һава» (366 мөрәҗәгать), «Су» (190 мөрәҗәгать) категорияләрендә кергән.

Законсыз чүплекләр төзү мәсьәләләре буенча гражданнардан иң күп мөрәҗәгатьләр - Казан (298 мөрәҗәгать), Чаллы (58), Яшел Үзән (46), Питрәч (39), Тукай (36), Лаеш (35), Түбән Кама (33), Биектау (31) Әлмәт (23) һәм Алабуга (21) районнары буенча бастырып чыгарылган.

Гражданнар мөрәҗәгатьләренең үтәлеше мониторингын гамәлгә ашыру кысаларында, без, җирле үзидарә органнары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары һәм контроль-күзәтчелек органнары вәкилләре белән берлектә, гражданнар хәбәрнамәләрендә күрсәтелгән объектлар буенча законсыз чүплекләр барлыкка килү, калдыкларны вакытында алып китмәү булган урыннарга чыктык һәм Казан шәһәрендә, Әлмәт, Биектау, Яшел Үзән һәм Лаеш муниципаль районнарында аларның туплану урыннары тиешенчә тотылмавын ачыкладык. Әлеге тикшерүләр нәтиҗәләре буенча законсыз чүплекләр бетерелде, мөрәҗәгатьләр үз чишелешен тапты.

«Халык контроле» системасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау барышында, безнең тарафтан шулай ук җаваплы башкаручыларның «Хәл ителде» статусын вакытыннан алда бирү очраклары ачыкланды.

Әйтик, Казан шәһәренең Киндерле, Салмачы һәм Яңа Царицыно торак массивлары территориясендәге санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү мәсьәләсе буенча «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасына килгән мөрәҗәгатьләрнең сыйфатсыз үтәлеше факты ачыкланды. Әлеге шикаятьләр буенча җаваплы башкаручылар тарафыннан «Хәл ителде» статусы бирелгән. Мониторинг барышында мөрәҗәгатьләр, аларны хәл итү турында мәгълүмат бирелмәү сәбәпле, эшкә кире кайтарылды. Соңыннан җаваплы башкаручылар тарафыннан мәгълүмат системасында әлеге мөрәҗәгатьләрне үтәү буенча тиешле чаралар күрү

турында мәгълүмат чагылдырылган. Хәзерге вакытта күрсәтелгән чүплекләр бетерелгән.

Ел дәвамында законсыз чүплек барлыкка килү турындагы шикаятьләр Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать итү предметы булды.

Мөрәҗәгатьләр килгәндә Вәкаләтле вәкил тарафыннан материаллар соратып алынды һәм өйрәнелде, прокуратура органнары һәм башка компетентлы органнар тарафыннан тиешле тикшерүләр башланды, мөстәкыйль тикшерүләр үткәрелде.

2024 елның октябрендә Вәкаләтле вәкил адресына граждан М. мөрәҗәгать иткән. Мөрәҗәгать итүче үзенең мөрәҗәгатендә билгесез затлар тарафыннан Казан шәһәренең Айдаров һәм Кутузов урамнарындагы күпфатирлы йортларга якын урнашкан, элек каты коммуналь һәм габаритлы калдыклар өчен контейнерлар һәм бункерлар урнашкан муниципаль территориягә даими рәвештә төрле калдыклар китерелүен, бу законсыз чүплек барлыкка килүгә китерүен әйткән. Җилле һава торышы вакытында бу чүплектән чыккан калдыклар бөтен тирә-якка, шул исәптән якындагы балалар мәйданчыгына да таралган.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары хакимияте һәм Вәкаләтле вәкил Аппараты уртак эше йомгаклары буенча мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән законсыз чүплек юкка чыгарылды һәм йорт яны территориясе тиешле тәртипкә китерелде.

Ел саен безнең республикада 1,47 млн. тонна калдык хасил була, шулардан 1,23 млн.тонна калдык аларны зарарсызландыру һәм күмү өчен махсус полигоннарга урнаштырыла. Чүп полигоннарында урын җитмәү кискен проблемаларның берсе булып кала. Росприроднадзорның Идел-Кама төбәкара идарәсе мәгълүматларына караганда, 2025 елда бөтен республикага бары тик 16 полигон гына хезмәт күрсәтәчәк. Актаныш, Менделеев, Сарман, Чирмешән һәм башка районнарда полигоннарның сыйдырышлылыгы беткән. Узган елда шулай ук Азнакай, Арча, Кама Тамагы һәм Тәтеш муниципаль районнарындагы полигоннарда урыннар бетте. 2024 елның декабрь азагында шулай ук Казанның Химия урамындагы калдыклар полигоны ябылды, 2025 елда аны рекультивацияләү эшләрен башлау планлаштырыла. Хәзер Казан шәһәре территориясеннән калдыклар хисап елында файдалануга тапшырылган «Восточный» полигонының икенче картасына китерелә.

Югарыда бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына җирле үзидарә органнары һәм көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча төбәк операторлары белән берлектә, чүп өчен яңа махсуслаштырылган полигоннарны гамәлгә кертү чараларын вакытында гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәбез.

**Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү**

2024 елда каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк операторлары эшчәнлеген карау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының эшче штабы (алга таба – штаб), көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча төбәк операторлары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре катнашында үз эшен төгәлләде. Вәкаләтле вәкил һәм аның вәкилләре дүрт ел дәвамында эш штабы утырышларында актив катнашты, алар барышында аерым муниципаль берәмлекләр һәм шәһәр округлары территорияләреннән каты көнкүреш



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 237 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

калдыкларын вакытында чыгармау мәсьәләләре буенча гражданнарның 1 000нән артык шикаяте каралды.

Штаб эшләү дәверендә профильле министрлыклар һәм ведомстволардан коллегалар белән берлектә калдыклар белән эш итү өлкәсендә берничә системалы проблема хәл ителде, шул исәптән безнең республикада контейнер мәйданчыклары реестры, шулай ук санитария кагыйдәләре таләпләренә туры китереп каты көнкүреш калдыклары чыгару графигы актуальләштерелде.

Хисап елында «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына «Каты коммуналь калдыклар» юнәлеше буенча 4 318 мөрәҗәгать керде, бу узган елның шушы чоры белән чагыштырганда 21% ка күбрәк (3 577), бу безнең республикада калдыклар белән эш итү проблемасының актуальлеген күрсәтә.

Әйтик, 2024 елның кышкы чорында Казан шәһәре, Яшел Үзән, Лаеш, Питрәч һәм «ПЖКХ» ИК» ҖЧҖнең каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча төбәк операторы эшчәнлеге зонасына караган башка муниципаль районнар халкы чүп-чарны вакытында чыгармау проблемасына юлыккан, бу мул кар явуга һәм шуңа бәйле рәвештә чүп туплану урыннарына керү юлларының кар белән каплануына бәйле булган. Узган елның беренче кыш айларында төбәк операторы адресына әлеге проблема буенча 500дән артык мөрәҗәгать килгән.

Гражданнардан күп санда шикаятьләр килү һәм аларны оператив хәл итәргә кирәк булу сәбәпле, Вәкаләтле вәкил 2024 елның февралендә «ПЖКХ» ИК» ҖЧҖ генераль директоры адресына мөрәҗәгать итте. Безнең катнаштан соң төбәк операторы оператив тәртиптә 100 дән артык мөрәҗәгатьне хәл итте һәм чүп-чарны чыгару вәзгыяте тотрыкланды.

Вәкаләтле вәкил, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча төбәк операторларының җирле үзидарә органнары белән бергәләп эшләвен һәм тыгыз хезмәттәшлеген дәвам итүгә өмет белдерә.

2024 елда Вәкаләтле вәкилгә шулай ук каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча хезмәтләр өчен түләүне законсыз исәпләүгә бәйле мөрәҗәгатьләр килүен дәвам итте.

Әйтик, безнең адреска граждан Ш.ның Балык Бистәсе муниципаль районында яшәүче улы мәнфәгатьләрендә, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтү өчен исәпләнә торган түләү белән килешмәү турында мөрәҗәгате килде. Мөрәҗәгать итүченең улы төзелеп бетмәгән, беркем дә яшәмәгән һәм хуҗалык эшчәнлеге алып барылмаган йортның милекчесе булган. Әлеге фактларга карамастан, «ПЖКХ» ИК» ҖЧҖ тарафыннан каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча хезмәт күрсәткән өчен түләү исәпләнгән.

Мөрәҗәгатьне карау барышында, без, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең гавами кадастр картасы белешмәләрен анализладык, алар мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча теркәлгән корылмалар булмау фактын һәм мөрәҗәгать итүченең улына чүп өчен түләүнең законсыз булуын раслады. Алынган мәгълүмат безнең тарафтан төбәк операторы адресына җибәрелде, аның нәтиҗәләре буенча калдыклар өчен түләү яңадан исәпләнде һәм 10 мең сумнан артык түләү кире кайтарылды.

**Су объектларын саклау**

Экологик иминлеккә бәйле тагын бер мөһим аспект - су ресурсларын саклау.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 238 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан - илнең төче су белән тәэмин ителгән төбәкләренең берсе. Республика территориясендә 36 меңнән артык су объекты урнашкан.

Республикада елгаларның һәм сулыкларның экологик торышын яхшыртуга зур игътибар бирелә. Якындагы елларда «Россия суы» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында, Яр Чаллы шәһәрендә Мәләкәс елгасы үзәнен һәм Казан шәһәрендә кушылдыклары булган Нокса елгасын чистарту буенча чаралар үткәрү планлаштырыла. Аларны гамәлгә ашыруга 1 млрд. сумнан артык акча бүлеп бирү планлаштырылган. Шулай ук әлеге проект кысаларында 2025 елда Казан шәһәренең биологик чистарту корылмаларының ләм кырларын рекультивацияләү эшләрен төгәлләү ниятләнә.

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында «Су» категориясе буенча иң күп мөрәҗәгатьләр Казан шәһәре (80 мөрәҗәгать), Лаеш муниципаль районы (19), Чаллы шәһәре (16), Биектау (10), Яшел Үзән (10), Әлмәт (9) муниципаль районнары буенча бастырылган.

Әйтик, гражданка Ф. «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасына җибәргән мөрәҗәгатендә Әлмәт шәһәренең Бигәш елгасына канализация торбасы аша агып төшүче калдык сулар эләгүе турында хәбәр иткән.

Экология министрлыгы тарафыннан әлеге мөрәҗәгатьне карау йомгаклары буенча, системада табигатьне саклау законнарының мәҗбүри таләпләрен мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән торбаны бетерү юлы белән бозарга ярамавы турында кисәтү ясалу турында җавап урнаштырылган. Әмма системада җаваплы башкаручыларның эшен мониторинглау барышында безнең тарафтан әлеге мөрәҗәгатьне үтәү буенча конкрет чаралар күрелмәве ачыкланды, шулай ук Экология министрлыгына хат җибәрелгәннән соң хокук бозучыга әлеге кисәтү бирелмәве ачыкланды.

Шулай ук безнең тарафтан Кукмара муниципаль районында сулыкларның саегуы проблемасы буенча хәбәрнамә дә билгеләп үтелде. Әлеге шикаятькә «Хәл ителде» статусы бирелүгә игътибар бирелде, әмма билгеләнгән проблеманы хәл итү буенча чаралар күрелмәде.

Ачыкланган фактларга бәйле рәвештә, гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын яклау максатларында, Вәкаләтле вәкил тарафыннан Экология министры адресына күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне үтәү буенча тулы чаралар күрү турында тәкъдимнәр җибәрелде.

Нәтиҗәдә, Әлмәт муниципаль районында, министрлык катнашканнан соң, әлеге шикаять кабат каралды. Җаваплы затлар тарафыннан күрсәтелгән коега яңгыр торбасы тампонажы ясалды һәм Бигәш елгасына калдык сулар агызу туктатылды.

Кукмара муниципаль районында Экология министрлыгы тарафыннан безнең инициатива белән үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча сулык урнашкан җир кишәрлеген файдалануга законсыз бирү факты ачыкланды. Әлеге мәгълүмат прокурор чараларын күрү өчен Татарстан районара табигатьне саклау прокуратурасына җибәрелгән иде.

Прокуратура органы, Экология министрлыгы дәлилләре белән килешеп, ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы тәкъдимне кертте. Хәзерге вакытта күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан алынган күчермәдән күренгәнчә, күрсәтелгән җир кишәрлегенең милекчесе юк.

Шуңа бәйле рәвештә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы башкарма хакимият органнарына, әйләнә-тирә мохитне саклау



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 239 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31

өлкәсендә таләпләрне үтәүне контрольдә тотучы затларга бирелгән кисәтүләрнең үтәлешен тикшереп торуны көчәйтергә тәкъдим итәбез.

Мөрәҗәгатьләрне мониторинглау барышында, шулай ук системаның 200дән артык кулланучысы хуплаган Константиновка торак массивындагы күлне корылыктан коткару кирәклеге турындагы хәбәргә игътибар юнәлтелде. Хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручылар тарафыннан хәбәрнамәгә системада «Хәл ителде» статусы бирелгән, әмма әлеге проблеманы хәл итү буенча нәтиҗәле чаралар күрелмәгән, шуңа бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасына табигатьне саклау законнарын бозу факты буенча тикшерү уздыруны һәм прокурор чараларын күрүне сорап мөрәҗәгать итте.

Без башлап җибәргән тикшерү нәтиҗәсендә прокуратура органы тарафыннан хокук бозулар ачыкланды һәм гаепле затлар адресына аларны бетерү турындагы тәкъдимнәр кертелде, алар бүгенге көнгә үтәлде.

Шулай ук узган ел дәвамында, безнең катнашуыбыздан соң, Марьино күлен пычрату һәм Кече Акчарлак күле буенда объектларны һәм корылмаларны хокуксыз урнаштыру турындагы мөрәҗәгатьләр буенча чаралар күрелде.

Узган елда гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокуклары бозылу ихтималы турындагы мәгълүматны тикшерү кысаларында, Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре контроль-күзәтчелек органнары, җирле үзидарә органнары һәм юридик затлар вәкилләре белән берлектә күчмә тикшерү чараларында катнашты.

2024 елның июлендә Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы вәкилләре белән берлектә, Минзәлә муниципаль районында чистарту корылмасыннан файдаланганда су агызу тәртибен җайга сала торган законнарның үтәлешен тикшерүдә катнашты.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча хокук бозулар ачыкланды һәм прокуратура органы Минзәлә район судына табигатьне саклау законнарын бозуларны бетерү һәм ташландык суларны норматив чистартуны тәэмин итү турында Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты һәм «Коммуналь челтәрләр» АҖ адресына дәгъва юллады. Суд дәгъваны канәгатьләндерде.

**Гражданнарның чиста эчәр суга хокукы**

Кешенең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә һәм чиста эчә торган суга хокукы белән турыдан-туры бәйле

Ел саен Татарстан Республикасында халыкны эчәр су белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга шактый финанс чаралары бүлеп бирелә.

2024 елда республикада 159,44 км сүүткәргеч челтәр, 22 артезиан скважинасы һәм 26 су җыю башнясы төзелде (төзекләндерелде).

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан, 2024 елда республикада эчә торган суның сыйфаты һәм куркынычсызлыгы буенча 36,5 меңнән артык тикшеренү уздырылган. Санитар-химик һәм микробиологик күрсәткечләргә тест уздырыла торган канәгатьләнерлек булмаган үрнәкләр өлеше 1,8% тәшкил иткән, бу тулаем Россия Федерациясе белән чагыштырганда түбәнрәк. Татарстан Республикасы халкының 96% ка якыны сыйфатлы эчәр суны үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларыннан ала, ә бу күрсәткеч шәһәр халкы арасында 99% ка җитә.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 240 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы Рәисе Р. Н. Миңнеханов карары буенча 2025 елда 10 миллиард сумлык торак-коммуналь инфраструктурасын яңарту программасы эшли башлый. Яңа программа кысаларында максатчан чараларны тормышка ашыру, һичшиксез, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге кискен проблемаларны этаплап хәл итәргә, шул исәптән эчә торган су сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

Күрелгән чараларга карамастан, су белән тәэмин итү проблемалары республикада яшәүчеләрне борчый, бигрәк тә җәйге чорда.

Әйтик, 2024 елда торак пунктларда су белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында 1 323 мөрәҗәгать басылып чыккан, татарстанлылар бу сорау белән «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы аша 1000 тапкырдан артык мөрәҗәгать иткәннәр. Әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгатьләрне хәл итүне даими нигездә Вәкаләтле вәкил Аппараты тикшереп тора.

Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәренең Малые Клыки торак массивында Татарстан урамындагы индивидуаль торак йортларны үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү челтәрләренә технологик тоташтыруда ярдәм күрсәтү турында гражданка С.мөрәҗәгате кергән.

Мөрәҗәгать итүче үзенең мөрәҗәгатендә Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль предприятиесенең 2024 елның май аеннан җирле халыкның йорт биләмәләрен су белән тәэмин итү системасына тоташтыру проектын карау срокларын сузуын, шуңа бәйле рәвештә гражданнарның инде озак вакыт үзәкләштерелгән су белән тәэмин итүдән мәхрүм калуларын күрсәтте.

Кайбыч муниципаль районында яшәүче Вәкаләтле вәкилгә су колонкасын ремонтлауда ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгать иткән.

Югарыда аталган муниципаль берәмлекләрнең җаваплы затларына мөрәҗәгатьләребездән соң, күрсәтелгән проблемалар уңай чишелеш тапты.

Хисап елында Вәкаләтле вәкил, җирле үзидарә органнары һәм гарантия бирә торган оешмалар җитәкчеләренә мөрәҗәгатьләрне карау йомгаклары буенча, торак пунктларда эчәргә яраклы чиста суга хокукны яклауда һәм су белән озак тоткарлык булдырмау максатларында 30дан артык хат һәм тәкъдимнәр юллады.

Экологияне яхшырту һәм башкала халкына яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру Вәкаләтле вәкил контролендә кала.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 241 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31

# 5-НЧЕ БҮЛЕК. МӘҖБҮРИ ТОТУ УРЫННАРЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

## 5.1. Гражданнарны вакытлыча тоту урыннарында кеше хокукларын яклау

Татарстан Республикасының Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2024 елның 11 аенда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан вакытлыча тоту изоляторларында 15 835 шикләнелүче һәм гаепләнүче (тәүлегенә уртача - 158 кеше), махсус кабул итү урыннарында – административ кулга алынган 15 533 зат (тәүлегенә уртача – 244 кеше), тоткарланган затларны тоту өчен махсус биналарда – 35 656 кеше ( тәүлегенә уртача -107 кеше) тотылган.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы структурасында шикләнелүче һәм гаепләнүче затларны вакытлыча тоту өчен 40 изолятор, административ кулга алынган затларны тоту өчен 9 махсус кабул итү урыны, Россия Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсенең чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәге, шулай ук тоткарланган затларны тоту өчен 201 махсус бина бар.

Эчке эшләр органнарының мәҗбүри тоту урыннарында махсус контингентны тоту шартлары елдан-ел яхшыра. Федераль һәм төбәк бюджетларыннан бүленгән ассигнованиеләр кысаларында Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлекләрендә ремонт эшләре башкарылды.

Эчке эшләр министрлыгының Биектау һәм Мамадыш районнары буенча бүлекләре ремонтланды, Чирмешән районы бүлегендә шлюз төзекләндерелде, Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлегенең яңа бинасы төзелеше дәвам итте, анда шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту изоляторы җиһазландырыла.

2024 елда Вәкаләтле вәкил гражданнарны вакытлыча тоту изоляторларында, махсус кабул итү урыннарында һәм административ тәртиптә тоткарланучылар өчен биналарда тоту шартларын тикшерүне дәвам итте.

Хокук яклау эшенең төп юнәлеше кысаларында вакытлыча тоту урыннарында булган затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга кагылышлы 64 мөрәҗәгать каралды. Һәрбер мөрәҗәгать буенча тикшерү контроль-күзәтчелек органнары белән берлектә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе, муниципаль берәмлекләрдә, шәһәр округларында Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчеләре белән үзара хезмәттәшлектә үткәрелә.

Вакытлыча тоту урыннарындагы затларның хокуклары гарантияләрен ныгыту юлларын эзләүгә безнең тарафтан зур әһәмият бирелде. Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советы утырышында (24.12.2024) мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итүнең проблемалы мәсьәләләре, шулай ук ел дәвамында уздырылган мониторинг эшчәнлеге нәтиҗәләре турында фикер алыштылар.

Расланган график кысаларында Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы Аппараты хезмәткәре белән берлектә мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын саклау мәсьәләсенә кагылышлы Россия Эчке эшләр министрлыгының 19 муниципаль районындагы бүлекләрендә (Азнакай, Актаныш, Әлмәт, Апас, Баулы, Бөгелмә, Буа, Чүпрәле, Зәй, Лениногорск, Минзәлә, Мөслим, Сарман, Тәтеш, Ютазы районнары буенча, Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан»



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 242 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

муниципальара бүлегендә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча, Чаллы шәһәре, Түбән Кама районы буенча идарәләрендә) тикшерүләр үткәрелде.

Вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре гражданнарны кыска вакытлы мәҗбүри тоту урыннарына барып, биналарны карап чыгуга, аларның матди-техник җиһазлануына гына игътибар итмиләр, тоткарланучылар белән шәхси әңгәмәләр уздыралар, аларга консультацияләр бирү, кирәк булганда язма мөрәҗәгатьләр рәсмиләштерү өстенлекле әһәмияткә ия.

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре, шулай ук Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә тоту шартларын тикшерү максатларында Казан шәһәренең 2 нче «Вишневский», 10 нчы «Промышленный», 16 нчы «Япеев», 17 нче «Ямашев» полиция бүлекләрендә булдылар.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре махсус учреждениеләрендә тотылучы затларның хокукларын үтәү, тоту шартларының билгеләнгән таләпләргә туры килүен саклау буенча даими нигездә үткәрелүче чараларның зур күләмле булуына карамастан, тикшерүләр кысаларында тотылучы затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуның аерым очракларына игътибар бирелде.

Тикшерү барышында шикләнелүче А. Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсендә шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту изоляторында (08.07.2024 елдан) тикшерү үткәрү датасына (11.07.2024) кадәр көн саен бер сәгатьтән дә ким булмаган саф һавада булу хокукыннан файдалана алмавын язган.

Килү вакытында кайбер камералар канәгатьләнерлек булмаган хәлдә, шулай ук камераларда һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама буенча идарәсе вакытлыча тоту изоляторы ярдәмче биналарында көн дәвамында шикләнелүчеләрнең (гаепләнүчеләрнең) тормыш һәм сәламәтлек куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында билгеле бер дәрәҗәдә чисталык (визуаль һәм гигиена) сакланмаган.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Буа районы буенча махсус учреждениеләрендә булганда шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту изоляторы тикшерелде, аның нәтиҗәсендә стенада тирән ярык булу аркасында бер камераның куркынычсызлык таләпләренә җавап бирмәве ачыкланды.

Әлеге хәлләр булмаска тиеш, дип санап, тикшерү йомгаклары буенча Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Эчке эшләр министры адресына тиешле тоту шартларын тәэмин итү буенча чаралар күрү кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрде. Хатыбызны карау нәтиҗәләре буенча аларны бетерү буенча чаралар күрелде.

Учреждениеләргә чыкканда, Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре Вәкаләтле вәкилнең узган елларда җибәрелгән тәкъдимнәренең чынлыкта үтәлүенә игътибар иттеләр. Безнең тарафтан 16 нчы «Япеев» полиция бүлегендә уңай үзгәрешләр күзәтелүе билгеләп үтелде. 2023 елда без урын-җирне юылган һәм кулланышта булган кер белән бергә шкафта саклануны ачыкладык. Безнең әлеге категориядәге затларны тотуның тиешле шартларын үтәү буенча чаралар күрү кирәклеге турындагы тәкъдимнәр исәпкә алынды һәм 2024 елда әлеге кимчелек бетерелде.

Казан шәһәре полиция бүлекләрендә булганда игътибар, административ хокук бозулар өчен тоткарланган затларны камераларда тотуга, шулай ук гражданнарны китергәннән соң Россия ЭЭМ территориаль органының дежур өлешендә полиция



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 243 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

вазыйфаларын башкару һәм хокукларын гамәлгә ашыру тәртибе турындагы күрсәтмә белән билгеләнгән оператив дежур вазыйфаларын үтәүгә бирелде (Россия ЭЭМ 30.04.2012 № 389 боерыгы).

10 нчы «Промышленный» полиция бүлегендә (килү датасына 14.11.2024, 09:55) Үзбәкстан Республикасы гражданы тотылган, 13.11.2024 14:20 сәгатьтә урнаштырылган, (килү датасына 14.11.2024, 11:34) 12 сәгатьтән артык «Вишневский» ның 2 нче полиция бүлегендә ике чит ил гражданы тотылган: Төрекмәнстан Республикасы гражданы (махсус бүлмәләргә урнаштырылган 13.11.2024 сәгать 09:50) һәм Таҗикстан Республикасы гражданы (махсус биналарга урнаштырылган 13.11.2024 17:50).

Тикшерү барышында без, билгеләнгән тәртип белән, каралган срокта Россия Федерациясе территориясендә эшләүче дипломатик вәкиллекләргә яисә консуллык учреждениеләренә хәбәр ителмәвен ачыкладык. Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе вәкилләре белән берлектә полиция бүлекләренең вазыйфаи затларына тиешле вазыйфаларны башкарырга тәкъдим итте.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсендә шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту изоляторы хезмәткәрләре конвойга озатканда шикләнелүчеләргә һәм гаепләнүчеләргә карата хөрмәтсез мөнәсәбәт белдерү һәм башка борчый торган мәсьәләләр турында хәбәр ителгән мөрәҗәгатьләр, шикләнелүчеләрне вакытлыча тоту изоляторларының эчке тәртип кагыйдәләре таләпләрен саклауга кагылышлы сораулар Вәкаләтле вәкилдә борчу тудырды.

Шул сәбәпле Вәкаләтле вәкил тарафыннан тикшерү оештырылды. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы һәм Яр Чаллы шәһәре прокуратурасы вәкиле белән берлектә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсендә шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту изоляторына бару оештырылды.

Тикшерү барышында затлардан сораштыру үткәрелде.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча Идарәсе тарафыннан шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту изоляторында тикшерү уздырган вакытта тикшерүгә тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнү нәтиҗәләре буенча гражданнарга физик көчне нигезсез куллану турындагы дәлилләр расланмадылар.

Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүчеләрнең дәлилләрен карау кысаларында гаепләнүченең тикшерү чаралары барышында тартып алынган әйберләренең хокукый торышын билгеләү өлешендә документларның тиешенчә рәсмиләштерелмәвенә игътибар бирелде. Моңа бәйле рәвештә Яр Чаллы шәһәре прокуратурасы тарафыннан федераль закон бозуларны бетерү турында күрсәтмә кертелде, ул Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе тарафыннан канәгатьләндерелде.

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы һәм аның территориаль бүлекчәләре җитәкчелеге тарафыннан гражданнарның, кыска вакытлы мәҗбүри булу урыннарына урнаштырылган затларның хокукларын бозуны булдырмаслык шартлар тудыру эшен дәвам итәчәгенә ышаныч белдерә.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 244 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## 5.2. ҖИНАЯТЬ-ҮТӘҮ СИСТЕМАСЫ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

### 5.2. Җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендә кеше хокукларын яклау

Россия Федерациясе Конституциясе белән кеше һәм граждан ирекләрен дә, шул исәптән мәҗбүри тоту урыннарында җәза үтәүче затларга да хокукларны яклау гарантияләнә. Әлеге затларның хокуклары аларның хокукый статусы үзенчәлекләре белән чикләүләргә дучар, әмма шул ук вакытта законнарда каралган хокукларның үтәлешен тәэмин итү һәм әлеге категория гражданнарның законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук аларны тоту таләпләрен үтәүне тәэмин итү – вәкаләтле органнарның һәм вазыйфаи затларның турыдан-туры бурычы.

Ел саен җинаять-үтәтү законнары кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклауны арттыру максатларында камилләштерелә. 23.03.2024 № 60-ФЗ Федераль законы белән төзәтү учреждениесе администрациясе тарафыннан, бер ел эчендә ирегеннән мәхрүм итүгә хөкем ителгәннәргә техник мөмкинлекләре булмаганда телефоннан сөйләшү өчен бирелгән вакыт ел дәвамында алтыдан уникегә кадәр арттырылды, ундүрт яшькә кадәрге балалары булган шикләнелүчеләргә һәм гаепләнүчеләргә алар белән ай дәвамында өстәмә күрешү хокукы бирелде.

2024 елда шулай ук Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 399 маддәсенә үзгәрешләр кертелде, алар нигезендә хөкем ителүчене каты авыру сәбәпле җәза үтәүдән азат итү өлешендә суд карары кичекмәстән үтәлергә тиеш.

Җинаять сәясәтен гуманлаштыру шартларында, иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәзаларның альтернатив төрләрен куллану практикасын киңәйтү шартларында, республикада җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә хөкем ителүчеләр саны кимү тенденциясе күзәтелә.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматы буенча, 2024 елда ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдәге затларның саны 6 046 кеше тәшкил иткән, бу узган хисап чорына караганда 2,8 тапкырга кимрәк

Җәза үтәүчеләрнең җәмгыятьтән изоляция белән бәйле булмаган өлеше елдан-ел арта. Иректән мәхрүм итүгә альтернатив җәзаларның берсе булып 2017 елның 1 гыйнварыннан төзәтү үзәкләрендә башкарыла торган мәҗбүри эшләр тора. Әлеге төр җәзаның максаты - хөкем ителгәннәрне эшкә мәҗбүри җәлеп итү аша төзәтү һәм җәмгыятькә яраклаштыру. Институтның нәтиҗәлелеге практика белән расланган.

Хөкем ителгәннәр хокукларының закон чыгару һәм социаль-икътисадый гарантияләрен ныгыту буенча дәүләт тарафыннан, мәҗбүри эшләр кулланылган гражданнарга карата эзлекле чаралар күрелә. Судлар бу төр җәзаны күпкә активрак куллана башладылар. Әйтик, 2023 елның 6 айда республикада мәҗбүри эшләрне күздә тоткан 25 хөкем карары чыгарылган, 2024 елның шул ук чорында - 43.

Хәзерге вакытта республика территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаны үтәтү-төзәтү үзәге, төзәтү учреждениесе каршындагы бер изоляцияләнгән участок һәм төзәтү үзәгенең 1266 кешене урнаштыру мөмкинлеге булган сигез участогы бар. Шул ук вакытта төзәтү үзәкләре 48,5% ка гына тулган.

Төзәтү үзәкләренең тулылану проценты артуга Россия Федерациясе Дәүләт Думасының законнарга үзгәрешләр кабул итүе ярдәм итәр, дип уйлыйбыз,



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 245 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

законнарда мәҗбүри эшләрне җәзаның мөстәкыйль төре буларак билгеләргә тәкъдим ителә. Әлеге закон проектлары пакеты Россия Федерациясе Дәүләт Думасы тарафыннан пленар утырышта беренче укылышта кабул ителде.

Дәүләт хокук яклау институтына йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру кысаларында һәм гамәлдәге законнарда, Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппаратында билгеләнгән компетенция чикләрендә, хисап елында гражданнарның хокукларын тәэмин итү һәм яклау буенча эш дәвам итте.

Хисап елында шикләнелүчеләрнең, гаепләнүчеләрнең һәм хөкем ителүчеләрнең хокукларын яклау мәсьәләләре буенча Вәкаләтле вәкил Аппаратына 397 мөрәҗәгать керде. Мөрәҗәгатьләрдә тиешле булмаган шартлар, канәгатьләнерлек булмаган медицина тәэминаты, дисциплинар җәзаны нигезсез салу, башкару эшчәнлеге турындагы законнарны бозу, билгеләнгән инвалидлык төркеме белән, администрация карары белән килешмәү, җәзаның үтәлмәгән өлешен җәзаның йомшаграк төре белән алмаштыру турындагы үтенечне канәгатьләндерүгә каршы чыгу, чыгарылган хөкем карары белән килешмәү, пенсия законнары мәсьәләләрен хәл итүдә, аларның торак хокукларын яклауда ярдәм итү турындагы сораулар иде. Моннан тыш, хөкем ителүчеләр еш кына хокукый консультация алу турында Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иттеләр.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең дәлилләрен тикшерү максатыннан, Вәкаләтле вәкилгә, һәм планлы тикшерүләр уздыру кысаларында Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан да, шулай ук Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкилләре белән бергә, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе карамагындагы учреждениеләргә 23 тапкыр чыгу оештырылды.

2024 елның 13 декабрендә Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасыннан Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Пермь крае буенча Баш идарәсенең Пермь тәрбия колониясендә җәза үтәүче балигъ булмаган хөкем ителгәннәр янында булды. 25 декабрьдә Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсенең 1 нче тикшерү изоляторына барды, анда ул шулай ук балигъ булмаганнарны тоту шартлары белән танышты.

Вәкаләтле вәкилнең проблемалы участокларны ачыклауга юнәлдерелгән хокук яклау эшчәнлегенең бер төренә хөкем ителгәннәр белән актив хезмәттәшлекне күздә тота торган, төзәтү, җәза үтәү учреждениеләрендә 2015 елдан бирле уздырыла торган «Хокукый ярдәм көннәре» керә.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе карамагындагы учреждениеләрдә «Хокукый ярдәм көне» республика министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләрен җәлеп итеп, төзәтү учреждениеләренә чыгып та, видеоконференцэлемтә форматында да үткәрелә.

2024 елда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе карамагындагы учреждениеләрдә 150 шикләнелүче, гаепләнүче һәм хөкем ителүче белән 13 «Хокукый ярдәм көне» үткәрелде. Үткәрелгән кабул итүләр нәтиҗәсендә хөкем ителүчеләрнең 37 мәсьәләсе уңай хәл ителде, 75 хөкем ителүчегә хокукый консультация бирелде.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 246 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Хөкем ителгәннәрнең арзан һәм сыйфатлы медицина ярдәменә хокукларын яклау**

Шикаятьләрне карау нәтиҗәләренә анализ ясау һәм суд, хокук куллану практикасын өйрәнү хөкем ителгәннәрнең хокукларын гамәлгә ашыруда һәм яклауда булган кайбер актуаль проблемаларны аерып күрсәтергә мөмкинлек бирә. Аларның берсе республика җинаять-үтәтү системасының тикшерү изоляторларында, төзәтү учреждениеләрендә медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле.

2024 елның 12 аенда төзәтү учреждениеләрендә хөкем ителүчеләрнең авыру күрсәткече узган елның шул чоры белән чагыштырганда 18,7% ка арткан.

Тиешле медицина ярдәме алуда ярдәм итү турында хөкем ителгәннәрдән Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьләр саны елдан-ел кимеми, пенитенциар категориядәге барлык мөрәҗәгатьләр структурасында өстенлек итә.

2024 елда әлеге учреждениеләрдә билгеләнгән дәвалауның нәтиҗәсезлеге, табиб-белгечләрдән озак вакыт консультацияләр көтү, диагностика чараларын үткәрмәү, сәламәтлек турында мәгълүмат алу мөмкинлеге булмау турында дәлилләр китереп, 50 мөрәҗәгать килде.

Учреждениеләрнең медицина часте хезмәткәрләренең гамәлләре белән килешмәүләрен белдереп, мөрәҗәгать итүчеләр диагнозны билгеләгәндә сәламәтлекнең канәгатьләнерлек булмаган торышына һәм дәвалау билгеләүгә кагылышлы шикаятьләрне исәпкә алмауларын әйттеләр. Шуңа бәйле рәвештә авыручыларга да, сәламәт кешеләргә карата да учреждение хезмәткәрләре таләпләрен үтәгәндә һәм режим таләпләрен үтәгәндә дә шундый ук таләпләр куела. Алар учреждениеләр хезмәткрләре таләпләрен үтәгәндә һәм режим таләпләрен үтәгәндә авырту кичергәннәрен, бу, үз чиратында, аларның сәламәтлеге начараюга китерүен хәбәр итте.

Һәрбер мөрәҗәгать безнең тарафтан индивидуаль каралды. Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатьләр авторларының сәламәтлек торышы турында мәгълүмат соратты, хокукларны яклау максатларында кичекмәстән чаралар күрү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итте, кайбер очракларда учреждениеләргә турыдан-туры үзе барды.

Күпчелек шикаятьләрне җентекләп өйрәнгәндә, аларда бәян ителгән дәлилләр расланмады. Кайбер очракларда Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатьләре буенча, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең МСЧ-16 учреждениесе мөрәҗәгать итүчеләргә өстәмә медицина тикшерүләре, диагностикалар билгеләде, дәвалау тактикасына үзгәрешләр кертелде, аларны дарулар белән тәэмин итү чаралары күрелде

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил адресына Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең КП-18 учреждениесендә җәза үтәүче П. дан операцияне тизрәк уздыруда ярдәм күрсәтү турында мөрәҗәгать кергән. Аңа югары технологияле медицина ярдәме квотасы буенча оча бот буынын эндопротезлау сорала. Мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Республика клиник хастаханәсе» баш табибы адресына мөрәҗәгать итте. Безнең хатны карау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә клиник хастаханәнең консультатив поликлиникасының югары квалификацияле категорияле табиб-терапевты консультация бирде, консерватив дәвалау курсы,



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 247 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

гастропатияне коррекцияләү максатыннан, оча бот буынын тоталь эндопротезлау өчен планлаштырылган госпитализацияләү датасы билгеләнде.

Хөкем ителгәннәргә ярдәм күрсәтү эшен камилләштерү максатларында, Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, МСЧ-16 учреждениесенә телемедицина технологияләрен кулланып, шул исәптән гражданлык сәламәтлек саклау учреждениеләрен җәлеп итеп, хөкем ителгәннәргә һәм сак астында тотылучы затларга медицина ярдәме күрсәтү практикасын киңәйтергә киңәш итә. Шулай ук мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга үз акчалары исәбеннән түләүле медицина хезмәтләре күрсәтү мөмкинлеген карарга тәкъдим ителде, аерым алганда, тешләрне дәвалау һәм теш протезлары ясау буенча, шул исәптән гражданлык сәламәтлек саклау учреждениеләре шартларында.

Сак астында торучыларга һәм хөкем ителгәннәргә тиешле медицина ярдәме күрсәтү сыйфатына йогынты ясый торган сәбәпләрнең берсе - кадрлар белән тәэмин ителеш.

2024 елның декабренә МСЧ-16 филиалларының медицина персоналы белән тәэмин ителеше 80 % тәшкил иткән.

Соңгы елларда эштән киткән табиблар саны кабул ителгәннәрдән күбрәк. Медицина персоналын җәлеп итү мөмкинлеге булмау, беренче чиратта, тулаем алганда, кадрлар тармагының кытлыгы, шулай ук төзәтү учреждениеләренең шәһәрләрдән, инфраструктурадан ерак булуы һәм, гомумән кешеләрнең шикләнелүчеләр, гаепләнүчеләр, хөкем ителүчеләр белән эшләү турындагы стереотиплары белән бәйле.

Медицина хезмәткәрләренең җитәрлек булмавы хөкем ителгәннәргә сәламәтлек саклауга үз хокукларын гамәлгә ашырырга һәм кирәкле медицина ярдәмен тулы күләмдә алырга комачаулый. Күп кенә хөкем ителүчеләр авыр хроник авырулардан интегә, шуңа күрә сыйфатлы һәм вакытында күрсәтелгән медицина ярдәме алар өчен бик мөһим.

Медицина персоналы җитмәү белән бәйле мондый вәзгыять тулы чаралар күрүне таләп итә, шуңа бәйле рәвештә Вәкаләтле вәкил хезмәт өчен түләү дәрәҗәсен арттыру, шулай ук җинаять-башкарма системасының медицина хезмәткәрләре өчен башка социаль гарантияләр билгеләүне сорап, Россия Федерациясе Хөкүмәтенә, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенә тиешле тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итәргә кирәк, дип саный.

Вәкаләтле вәкилгә шулай ук медик-социаль экспертизага юллама һәм инвалидлык төркемен билгеләүдә ярдәм күрсәтү турында мөрәҗәгатьләр дә керде. Мөрәҗәгатьләрне караганда, аерым очракларда медицина документларын медик-социаль экспертизага җибәрү срокларының озакка сузылуы күзәтелде.

Әйтик, 2024 елның февралендә Вәкаләтле вәкил адресына шикләнелүче Ф.инвалидлык төркеме алуда ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать иткән. Ул аны хастаханәгә җибәрүне сорап, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 3 нче тикшерү изоляторының медицина частенә клиник һәм лаборатор тикшеренүләр үткәреп, аның нәтиҗәләре буенча табиблык комиссиясе утырышы карарын кабул итү максатында берничә тапкыр мөрәҗәгать итүен әйтте.

Безнең Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең МСЧ-16 учреждениесенә мөрәҗәгатьтән соң, мөрәҗәгать итүченең медицина документлары



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 248 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

хөкем ителгәннәр өчен хастаханәдә дәвалану нәтиҗәләре буенча медик-социаль экспертизага җибәреләчәк һәм кабат тикшереләчәк, дип хәбәр ителде. Мәсьәләне озак вакыт хәл итмәү сәбәпле, Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең МСЧ-16 адресына кабат мөрәҗәгать итте. Бары биш айдан соң безгә мөрәҗәгать итүчегә инвалидлык төркеме билгеләнүе турында хәбәр ителде.

Медик-социаль экспертизага документларны җибәрү срокларын сузуга юл куймау максатларында, 2024 елның 24 декабрендә узган Вәкаләтле вәкил каршындагы мәҗбүри тоту һәм вакытлыча булу урыннарында кеше хокукларын үтәү мәсьәләләренә багышланган эксперт советы утырышында, Вәкаләтле вәкил тарафыннан әлеге проблемага Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең МСЧ-16 вәкилләренең аерым игътибары юнәлтелде.

## Төзәтү учреждениеләрендә җәза үтәүче инвалидларның хокукларын яклау

Пенитенциар система учреждениеләрендә тотылучы затларның хокукларын яклау өлкәсендә, шулай ук мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид булган затларны тоту шартлары да актуаль мәсьәлә.

2024 елның 30 декабренә республиканың җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә инвалидлыгы булган 266 кеше тотылган.

Ел дәвамында Вәкаләтле вәкил аларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү буенча аналитик эш башкарды. Әлеге анализ нәтиҗәләре Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә тотылган барлык хөкем ителүчеләрнең, инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин ителүе турында сөйли.

Инвалидлыклары булган хөкем ителүчеләрнең хокукларын яклау өлкәсендә узган елда, Вәкаләтле вәкил тарафыннан Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе учреждениеләрендә уңайлы мохит тәэмин итү мәсьәләләренә зур игътибар бирелде.

2021-2022 елларда Вәкаләтле вәкил Аппараты Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе белән бергә республиканың җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренә мониторинг үткәрде. Анда безнең тарафтан Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 3 нче төзәтү колониясе, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 5 нче төзәтү колониясе, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 8 нче төзәтү колониясе эшчәнлегендә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләрендәге инвалидларның тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү өлешендә аерым хокук бозулар ачыкланды.

Ачыкланган кимчелекләр буенча Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан башкарылган эшкә карамастан, бу мәсьәлә актуаль булып кала бирә.

Әйтик, 2024 елның декабрендә «Хокукый ярдәм көне» кысаларында Вәкаләтле вәкил адресына Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 3 нче төзәтү колониясендә җәза үтәүче гражданнардан өч мөрәҗәгать керде, болар гигиена процедураларын башкарганда кичерелә торган кыенлыкларга кагыла.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 249 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Мөрәҗәгатьләрдә хөкем ителүчеләр-инвалидларның мөмкинлекләре чикле инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып санитария узеллары җиһазландырылмаган гомуми отрядта яшәве хәбәр ителде, төзәтү учреждениесендә мунча-кер юу комплексы хөкем ителгән инвалидлар өчен сыгылмалы шланглар һәм табуретлар булган урыннар белән җиһазландырылмаган. Аз хәрәкәтләнүче гражданнарның мунча-кер юу комплексы буенча иркен йөри алмавына игътибар ителде, чөнки ул тоткалар белән җиһазландырылмаган.

Шундый ук проблема учреждение ашханәсендә дә бар иде.

Инвалидлар өчен уңайлы мохитне тәэмин итү максатларында, Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы адресына мөрәҗәгать итүчеләр бәян иткән дәлилләрне исәпкә алып, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле затлар өчен шартлар тудыру мөмкинлеген карау үтенече белән мөрәҗәгать итте. Докладны язган вакытта хат караудa иде.

### Хөкем ителүчеләрнең хокукларын үтәүнең аерым мәсьәләләре

Вәкаләтле вәкилнең хокук яклау эшчәнлегендә хөкем ителүчеләрнең хокукларын яклау буенча аерым чаралар, аларга Россия Федерациясе гражданы паспорты бирү; хөкем ителүченең гражданлыгын билгеләү; гражданлыгы булмаган затның шәхесен билгеләү мәсьәләләре буенча кабул ителде.

Әйтик, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең төзәтү учреждениеләрендә җәзаны үтәү мәсьәләләре буенча «Хокукый ярдәм көне» барышында хөкем ителгән С. , аңа Россия Федерациясе гражданы паспорты алуда булышуны сорап мөрәҗәгать итте, чөнки элек ул паспорт алмаган.

Вәкаләтле вәкил карамагында булган материалларга ярашлы рәвештә, 2023 елда миграция мәсьәләләре бүлеге С. гаризасы буенча шәхесне ачыклау процедурасын төгәлләгән.

Мөрәҗәгать итүчедә Россия Федерациясе гражданлыгы булуны билгеләү максатларында тиешле тикшерү оештырылган, аның нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясендә гражданлык мөнәсәбәтен билгеләү белән дәлилләнгән бәяләмә әзерләнгән. Бәяләмә расланганнан соң С.га Россия Федерациясе гражданы паспорты бирелергә тиеш була. Ләкин документлаштыру мәсьәләсе үз вакытында хәл ителмәгән.

С. дәлилләрен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил аның хокукларын яклау максатларында, Россия Федерациясе гражданы паспортын бирүне тизләтүдә ярдәм итүне сорап Татарстан Республикасы Эчке эшләр министры адресына мөрәҗәгать итте. Безнең мөрәҗәгать нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә паспорт бирелгән инде.

Хисап елында Вәкаләтле Вәкилнең игътибары Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте территориаль органнары карамагындагы учреждениеләрдә хөкем ителгәннәрнең мөлкәтенең саклanышын тәэмин итү мәсьәләсенә дә юнәлтелде.

Июль аенда Вәкаләтле Вәкилнең шәхси кабул итүе вакытында граждан О. тикшерү изоляторында сакланган шәхси һәм кыйммәтле әйберләрне җәза үтәү урыны буенча Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җәза үтә торган КП-18 учреждениесенә җибәрүдә ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итте.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 250 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Мөрәҗәгать итүче хәбәр иткәнчә, элегрәк ул Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Смоленск өлкәсе буенча идарәсенең тикшерү изоляторларының берсендә булган, анда аның шәхси һәм кыйммәтле әйберләре сакланган. Үз дәлилләрен раслап, мөрәҗәгать итүче кыйммәтле әйберләрне кабул итү (алу) актларын күрсәтте. Мөрәҗәгать итүче тикшерү изоляторында булганда ул, аңа карата суд карары законлы көченә кергән иректән мәхрүм ителүгә хөкем ителгән булу фактына, шулай ук җәзасын үтәр өчен республиканың төзәтү учреждениесенә җибәрелү фактына игъибарны юнәлтте.

Кирәкле ярдәм күрсәтү максатыннан Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Смоленск өлкәсе буенча идарәсе башлыгы адресына

хөкем ителүченең сакланган әйберләрен җибәрү мөмкинлеген карау үтенече белән мөрәҗәгать итте.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Смоленск өлкәсе буенча идарәсеннән килгән мәгълүматка ярашлы рәвештә, Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатен карау нәтиҗәләре буенча тикшерү үткәрелде, нәтиҗәдә кыйммәтле әйберләр җәзаны үтәү урыны буенча 2024 елның 8 июлендә һәм 2024 елның 19 августында җибәрелде.

**Наркотик чараларга һәм психоактив матдәләргә бәйлелеге булган хөкем ителгәннәрне реабилитацияләү**

2018 елдан Вәкаләтле вәкил берничә иҗтимагый оешма белән берлектә,

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2 нче төзәтү колониясендә һәм Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 19 чы төзәтү колониясе махсус төзелгән тернәкләндерү отрядлары базасында наркотик чараларга һәм психоактив матдәләргә бәйлелеккә эләккән хөкем ителгәннәрне реабилитацияләү буенча социаль проектны тормышка ашыра.

Җидееллык уңай эш чорында социаль проектны гамәлгә ашыруга һәрьяклап ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар уздырылды. 2024 елның 18 февралендә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 19 нчы төзәтү колониясендә эшләүче тернәкләндерү отряды 140 кв.метр мәйданлы бинадан 460 кв. метр мәйданлы яңа бирелгән бинага күчте, бу тернәкләндерү процессында бер мәртәбә булу өчен хөкем ителүчеләр санын 16дан 45 кешегә кадәр арттырырга мөмкинлек бирде.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе 19 нчы төзәтү колониясендә тернәкләндерү отряды эше өчен түбәндәге бүлмәләр бирелгән: индивидуаль һәм төркемләп дәресләр үткәрү өчен бүлмәләр; психиатр-нарколог кабинеты; китапханә; тренажер залы; җитештерү остаханәсе; йокы бүлмәләре. Тернәкләндерү отряды өч катлы бинаның икенче катында: беренче катында санитария части, ә өченчесендә мәгариф учреждениесе урнашкан, бу төзәтү колониясенең барлык социаль объектларын бер бинага берләштерергә мөмкинлек биргән.

Тотрыклы ремиссияне, терапевтик мохитне саклау һәм дәвамчанлыкны җайга салу максатында, яңа бинага элек стационар курс үткән һәм дәвалаудан соңгы программа узучы, әмма башка отрядларда яшәүче хөкем ителгәннәр дә күчерелде. Тернәкләндерү курсын узган кеше уникаль тәҗрибәгә ия һәм наркотикларга бәйле хөкем ителүченең нәрсә аша узуын аңлап, үзе белгәннәр белән уртаклашырга әзер.



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 251 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Барлык эш чорында, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 2 нче төзәтү колониясе һәм Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 19 нчы төзәтү колониясе тернәкләндерү отрядларыннан читтә торучы хөкем ителгәннәрнең тернәкләндерү курсын узу теләген формалаштыру максатыннан, 2700 дән артык мотивацион-мәгълүмати консультацияләр үткәрелде. Программаны гамәлгә ашыру чорында тернәкләндерү отрядларында 3800дән артык кече психотерапия төркеме, 1341 лекция, 484 тренинг, 7189 индивидуаль консультация үткәрелде. 405 хөкем ителүче пенитенциар учреждение шартларында реабилитацияләү программасын узды.

Әлеге практика Россия Федерациясендә уникаль булып тора.

2024 елның декабрендә тернәкләндерү отрядларының эшчәнлеге турындагы эш тәҗрибәсе белән танышырга Коми Республикасында, Санкт-Петербургта Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр һәм Ярославль өлкәсе Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре килде.

**Пенитенциар учреждениеләрдә ВИЧ-инфекцияне профилактикалау**

Вәкаләтле вәкил ярдәме белән гыйнвардан башлап 2024 елның октябренә кадәр Татарстан Республикасының төзәтү учреждениеләрендә «Татарстан Республикасының пенитенциар учреждениеләрендә ВИЧ-инфекцияне профилактикалау» проекты гамәлгә ашырылды. Аталган проект 2023 елда граждан җәмгыятен үстерүдә катнашучы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт ярдәмен тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирү бәйгесендә җиңүче булды.

Шулай ук проектның партнеры булып Россия Кызыл Хачның Татарстан төбәк бүлеге дә чыгыш ясады.

Проект кысаларында төзәтү учреждениеләрендә барлык кызыксынучылар өчен ВИЧ-инфекциягә аноним экспресс-тест үткәрелде, белем бирү һәм агарту чаралары үткәрелде.

Россия Кызыл Хачның Татарстан төбәк бүлеге белгечләре белән ВИЧ-инфекция турында хөкем ителгәннәрнең белемнәрен киңәйтүгә юнәлдерелгән лекцияләр, Вәкаләтле вәкил Аппараты вәкилләре катнашында юридик консультацияләр форматында Лекцияләр йомгаклары буенча теләгән һәркем үз соравын яисә хосусый рәвештә бирә алды. В проект кысаларында төзәтү учреждениеләрендә барлык кызыксынучылар өчен ВИЧ-инфекциягә аноним экспресс-тест үткәрелде, белем бирү һәм агарту чаралары үткәрелде

Россия Кызыл Хачның Татарстан төбәк бүлеге белгечләре белән ВИЧ-инфекция турында хөкем ителгәннәрнең белемнәрен киңәйтүгә юнәлдерелгән лекцияләр, вәкаләтле вәкил Аппараты вәкилләре катнашында юридик консультацияләр үткәрелде. Лекцияләр йомгаклары буенча теләгән һәркем үз соравын яисә шәхси рәвештә бирә алды.

2024 елның 10 аенда агарту чаралары кысаларында төзәтү учреждениеләрендә 22 тапкыр булдык.

Төзәтү учреждениеләрендә ВИЧ-инфекцияне профилактикалау - белемлерәк һәм сәламәт җәмгыяткә юл башы.

**Пробация институтын гамәлгә ашыру**



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 252 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Пенитенциар системасы учреждениеләрендәге затларның хокукларын яклау өлкәсендә Вәкаләтле вәкил эшчәнлегендәге мөһим бурычларның берсе -аларга җәзаны үтәгәннән соң җәмгыятькә уңышлы әйләнеп кайтуда ярдәм күрсәтү, рецидив җинаятьчелекне киметү.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү эшчәнлеген оештыру турында» 29.07.2019 № 631 карары нигезендә иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үтәгән һәм (яисә) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга дучар булган затларны җәмгыятькә реинтеграцияләү максатларында социаль-икътисадый, педагогик, хокукый характердагы чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

Чаралар комплексын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) төзелгән, ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссияләргә йөкләнде.

Ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнардан эшкә урнашуга ярдәм күрсәтү, даими яисә вакытлыча торак бирүдә, хокукый ярдәм алуда, социаль түләүләр алуда һәм башка мәсьәләләрдә булышу турындагы мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил 2024 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) ведомствоара комиссияләренең 2022 – 2024 елларга эшенә, аларның эшчәнлек нәтиҗәләренә мониторинг үткәрде.

2022-2024 елларда ресоциализацияләүгә ярдәм күрсәтүгә ризалык иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан Татарстан Республикасының Әлки, Кама Тамагы, Балык Бистәсе, Теләче муниципаль районнарында төзелгән ведомствоара комиссияләргә килде.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре һәм социаль яклау бүлекләре тарафыннан иректән мәхрүм итү урыннарыннан кайткан затларга, шулай ук иректән мәхрүм ителмичә хөкем ителгән затларга компетентлы органнарга мөрәҗәгать иткәндә кулай эш эзләүдә, эшкә урнашуда, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен алуда кирәкле ярдәм күрсәтелгән.

Шул ук вакытта үткәрелгән анализ нәтиҗәләре азат ителгән гражданнарның мәшгульлек үзәкләренә керүдән баш тартуларын күрсәтә.

Әйтик, Теләче районында 2022-2023 еллар һәм 2024 елның I кварталында Теләче районы буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә төзәтү колонияләреннән 14 гражданны иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында 14 хәбәрнамә тапшырылган. Шул ук вакытта азат ителгән гражданнар мәшгульлек хезмәтенә мөрәҗәгать итмәгәннәр.

Спас районында да шундый ук хәл. 2024 ел дәвамында мәшгульлек үзәгенә җәзаны үтәү учреждениеләреннән җәзасын үтәүче һәм азат ителгәннән соң даими яшәү урынына кайткан затлар турында җиде хәбәр килгән. Туры килерлек эш эзләүдә ярдәм сорап бер кеше мөрәҗәгать иткән, ул эшкә урнаштырылган.

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен квота бирү һәм эш урыннары резервлау турында» 24.07.2006 ел, № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларга инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
Страница 253 из 404. Страница создана: 25.02.2025 11:31
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланучы эш урыннары санын билгеләү турында» еллык карары нигезендә ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны эшкә урнаштырырга мөмкин булган резервланган эш урыннарына (һөнәрләргә) мәшгульлек елдан-ел теркәлми.

Әйтик, 2023 елда иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны эшкә урнаштыру өчен 44 эш урыны резервланган, әмма әлеге урыннарга барлыгы тугыз кеше эшкә урнаштырылган, 2024 елда 36 урын резервланган, дүрт кеше эшкә урнаштырылган.

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан чыккан затлар баш тартуны резервланучы аерым эш төрләренә (һөнәрләргә) тәкъдим ителгән вакансияләрдән кирәкле эш тәҗрибәсе булмау, эшләргә теләк булмау, сәламәтлекнең канәгатьләнерлек булмавы, вакытлыча эшләп алырга ризалык булу белән аңлата.

Түбәндәге системалы проблемаларның булуы да билгеләп үтелә: иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар күп санлы социаль һәм психологик проблемалар белән очраша, аларны хәл итү мөмкинлеге булмау аларның кабат җинаятьләр кылуына китерә. Килеп туган вәзгыятьнең сәбәпләре, беренче чиратта, торак булмау

яисә туганлык бәйләнешләренең югалуы, яшәү урыны буенча теркәү кыенлыгы, шәхесне таныклаучы документларның югалуы һ. б.

2024 елдан 06.02.2023 елгы «Россия Федерациясендә пробация турында» № 10-ФЗ федераль закон нигезендә башкарма һәм пенитенциар пробация институты эшли. Постпенитенциар пробация өлешендә положение 2025 елның 1 гыйнварыннан законлы көченә керде.

2023 – 2024 еллар дәвамында Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан әлеге Федераль законны гамәлгә ашыру буенча эш алып барылды: Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм пробация субъектлары, төрле оештыру-хокукый формадагы оешмалар арасында пробация кулланыла торган затларга ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында 242 килешү төзелде; коммерциячел булмаган, дини оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре белән эшлекле очрашулар үткәрелде. Пробация үзәкләре төзелергә мөмкин булган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар белән эш киңәшмәләре үткәрелде,

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Казан һәм Чаллы муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләренә күрсәтелгән оешмаларга ярдәм күрсәтү өчен мөрәҗәгатьләр җибәрелде; Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм алар карамагындагы учреждениеләр шәхси составы белән оештыру эше оештырылды.

Вәкаләтле вәкил «Россия Федерациясендә пробация турында» 06.02.2023 № 10-ФЗ Федераль законы кысаларында хөкем ителгәннәргә ярдәм күрсәтүне оештыру мәсьәләләре буенча фикер алышуга актив кушылды. Шулай ук ел дәвамында безнең тарафтан бу юнәлеш буенча аналитик эш алып барылды.

2024 елның 11 ае эчендә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә башкарма һәм пенитенциар пробация



Документ создан в электронной форме. № УПЧ-244 от 27.02.2025. Исполнитель: Мурсалимова А.И.
